СОВЕТ НИКОЛАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НИКОЛАЕВКА АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423722,Республика Татарстан,
Мензелинский район, с. Николаевка,
ул. Зеленая, д.7

423722, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Николаевка авылы , Зеленая урамы,7

телефон: (85555)2-49-23. E-mail: Nikol.Mnz@tatar.ru
ОКПО 04308212 ОГРН 1021605552726 ИНН/КПП
1628002788/162801001


Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Николаевка авыл жирлеге Советы

КАРАРЫ

№ 4 03.06.2019 ел

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Николаевка авыл жирлегендә
муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә турында

02.03.2007 елдагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы №25-ФЗ Федераль законы, 25.12.2008 елдагы "Коррупциягә каршы тору турында"гы №273-ФЗ Федераль законның үтәлеше өчен, 25.06.2013 елдагы №50-ЗРТ Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында Кодексы, "Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл жирлеге" Уставы белән Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл жирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл жирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта).

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл жирлеге Советының 11.04.2016 елдагы "Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл жирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмә турында"гы №1 карары көчен югалткан дип санарга.

3. Гамәлдәге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-коммуникацияле челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга һәм жирлек территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе : Нуриев А.М.

Минзәлә муниципаль районының
Николаевка авыл җирлеге
Советының № 4, 03.06.2019 ел.
карарына Кушымта

Минзәлә муниципаль районының
Николаевка авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

### 1. Җайга салу предметы

Гамәлдәге Нигезләмә Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәтне оештыру өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга сала, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт узу шартларын һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хокукый торышын (статус) билгели.

Гамәлдәге Нигезләмә белән депутатлар, җирле үзидарә органнары әгъзалары, җирле үзидарәнең сайланган вазифаи затлары, хәлиткеч тавыш хокукы булган даими нигездә гамәлдә булган һәм юридик затлар булган муниципаль берәмлекнең сайлау комиссияләре әгъзалары (алга таба – муниципаль берәмлекнең сайлау комиссияләре), муниципаль берәмлекнең контроль-исәп органы рәисе статусы билгеләнми, чөнки күрсәтелгән затлар (алга таба – муниципаль вазифаларны башкаручы затлар) муниципаль хезмәткәрләр булып тормый.

### 2. Муниципаль хезмәт

Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт – хезмәт килешүе (контракт) төзү юлы белән алыштырыла торган муниципаль хезмәт вазифаларында даими нигездә башкарыла торган, гражданнарның һөнәри эшчәнлеге.

2. Яллаучы вәкаләтләрен яллаучы (эш бирүче) вәкиле исеменнән башкара торган муниципаль берәмлек муниципаль хезмәткә яллаучы булып тора.

3. Яллаучы (эш бирүче) вәкиле булып Минзәлә муниципаль район Башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесе, Минзәлә муниципаль районы сайлау комиссиясе рәисе яисә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең вазифаларын башкарырга вәкаләтле башка зат булырга мөмкин.

### 3. Муниципаль хезмәтнең хокукый нигезләре

1. Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең хокукый нигезләрен Россия Федерациясе Конституциясе, 02.03.2007 елдагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы №25-ФЗ Федераль законы (алга таба - “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль закон) һәм башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасының башка законнары, Татарстан Республикасының

башка норматив хокукый актлары, “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, гамәлдәге Нигезләмә, гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарлар һәм башка муниципаль хокукый актлар төзи.

2. “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законында күздә тотылган үзенчәлекләр белән хезмәт законнарының тәэсире муниципаль хезмәткәрләргә кагыла.

## 4. Муниципаль хезмәтнең төп принциплары

Түбәндәгеләр муниципаль хезмәтнең төп принциплары булып тора:

1) кеше һәм гражданинның хокуклары һәм иреге өстенлеге;

2) Россия Федерациясенең дәүләт телен белүче гражданнарга муниципаль хезмәткә тигез керү хокукы һәм нинди иҗтимагый берләшмәләргә каравына, инануларына, дингә мөнәсәбәтенә, яшәү урынына, мөлкәти һәм вазифаи халәтенә, чыгышына, милләтенә, расасына, җенесенә, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатлары белән бәйләнмәгән башка вәзгыятькә бәйсез рәвештә аны узуда тигез шартлар булдыру;

3) муниципаль хезмәтләрнең профессионализмы һәм компетентлыгы;

4) муниципаль хезмәтнең стабильлеге;

5) муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге турында мәгълүматка керү мөмкинлеге;

6) иҗтимагый берләшмәләр һәм гражданнар белән үзара бәйләнеш;

7) муниципаль хезмәтләргә төп таләпләр бердәмлеге, шулай ук муниципаль хезмәт узганда тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алу;

8) муниципаль хезмәткәрләрнең хокукый һәм социаль яклангалыгы;

9) үз вазифаи бурычларын тиешенчә үтәмәгән яисә үтәмәгән өчен муниципаль хезмәткәрләрнең җаваплылыгы;

10) муниципаль хезмәтнең партиядә булмавы.

## 5. Россия Федерациясенең дәүләт һәм гражданлык хезмәте һәм муниципаль хезмәт арасында үзара бәйләнеш

Россия Федерациясенең дәүләт һәм гражданлык хезмәте һәм муниципаль хезмәт арасында үзара бәйләнеше (алга таба – дәүләт гражданлык хезмәте) түбәндәгечә тәэмин ителә:

1) дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын һәм муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен төп квалификацион таләпләр бердәмлеге;

2) дәүләт гражданлык хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне башкарганда вазифалар һәм чикләүләр бердәмлеге;

3) муниципаль һәм гражданлык хезмәте һәм һәм өстәмә һөнәри белем өчен кадрлар әзерләүгә таләпләр бердәмлеге;

4) муниципаль хезмәт стажын исәпләгәндә дәүләт гражданлык хезмәте стажын исәпләү һәм дәүләт гражданлык стажын исәпләгәндә муниципаль хезмәт стажын исәпләү;

5) дәүләт гражданлык хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең социаль гарантияләре һәм хезмәткә түләүнең төп шартлары нисбәте;

6) муниципаль хезмәт узучы гражданнарның дәүләт пенсиясе белән тәэмин ителешенең, һәм дәүләт гражданлык хезмәте узучы гражданнарның, шулай ук туйдыручысын югалткан очракта аларның гаилә әгъзаларының төп шартларының тәңгәллеге.

II. Муниципаль хезмәт вазифалары

6. Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифалары, муниципаль хезмәт вазифалары Реестры

1. Муниципаль хезмәт вазифасы – муниципаль вазифаны алмаштыручы затның яисә җирлекнең сайлау комиссиясе, җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен  башкаруны тәэмин итү буенча билгеләнгән вазифалар белән “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә булдырыла торган сайлау комиссиясе аппаратындагы, җирле үзидарә органындагы вазифа.
2. Муниципаль хезмәт вазифалары Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифалары Реестры нигезендә билгеләнә (гамәлдәге Нигезләмәгә Кушымта №1).

Николаевка авыл җирлегенең муниципаль вазифалар реестры тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып билгеләнә торган вазифаларның функциональ билгеләре һәм төркемнәре, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары буенча классификацияләнгән муниципаль хезмәт вазифалары атамалары исемлеген күздә тота.

3. Җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратының штат расписаниесен төзегәндә һәм раслаганда, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегенең муниципаль хезмәт Реестрында каралган муниципаль хезмәт вазифалары атамалары кулланыла.

4. Муниципаль хезмәт вазифаларының икеләтә атамалары түбәндәге очракларда мөмкин:

1) җирле үзидарә органының җитәкчесе урынбасары әлеге органның структур подразделениесе җитәкчесе булып тора;

2) җирле үзидарә органының структур подразделениесе җитәкчесе урынбасары әлеге органның структур подразделениесе җитәкчесе булып тора.

5. Җирле үзидарәнең башка органы (башка структур подразделениесе) җитәкчесе вазифасының атамасы “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән һәм (яки) башка муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә.

7.Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазифаларының үзара бәйләнеше, муниципаль хезмәт вазифаларының классификациясе

1. Муниципаль хезмәт вазифалары түбәндәге төркемнәргә бүленә:

1) муниципаль хезмәтнең югары вазифалары;

2) муниципаль хезмәтнең баш вазифалары;

3) муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазифалары;

4) муниципаль хезмәтнең өлкән вазифалары;

5) муниципаль вазифаларның кече вазифалары.

Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт һәм дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының үзара бәйләнеше Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларына һәм муниципаль хезмәтнең тиешле вазифаларына куела торган квалификацион таләпләрне исәпләп, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы белән билгеләнә.

8. Муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен квалификацион таләпләр

1. Муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру өчен профессиональ белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эшенә, вазифаи бурычларны башкару өчен мөһим булган белем һәм күнекмәләр, әзерлек юнәлешенә, шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә – яллаучының (эш бирүченең) вәкиленең тиешле карары булганда, квалификацион таләпләрнең тәңгәл килүе таләп ителә.

2. Һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен мөһим булган әзерлек юнәлешенә квалификацион таләпләр муниципаль хезмәт вазифалары классификациясе нигезендә Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә торган муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен типовой квалификацион таләпләр нигезендә, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.
Вазифаи бурычларны башкару өчен кирәкле булган белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификацион таләпләр муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясе һөнәри хезмәт эшчәнлеге төренә һәм өлкәсенә бәйле рәвештә билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясе белән шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификацион таләпләр дә күздә тотылырга мөмкин.

Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен белемгә (билгеле бер эшчәнлек өлкәсендә эш башкару мөмкинлеге бирүче һөнәри әзерлек барышында зат алган махсус белемнәр җыелмасы белем дип аңлашыла) түбәндәге типовой квалификацион таләпләр билгеләнә:

Муниципаль хезмәтнең кече һәм өлкән вазифалары буенча – Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының Конституцияләрен; Россия Федерациясенең һәм Татарстан Рспубликасының муниципаль хезмәт турында законнарын; “Татарстан Республикасының Николаевка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын; муниципаль хезмәт узуны оештыру нигезләрен; гражданнар белән эшне билгеләүче (гражданнар мөрәҗәгате белән)норматив-хокукый актларны, вазифаи бурычларны үтәүгә карата кулланыла торган эшчәнлекнең тиешле сферасын җайга салучы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең вәкиллекле һәм башкарма хакимияте органнары структураларын; гражданнарның персональ мәгълүматларын һәм мәгълүматны саклау буенча норматив-хокукый актларны; җирле үзидарә органының тиешле органы структураларын; тиешле вазифага кагылган оешмаларга һәм халыкка күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын; эш башкару нигезләрен, хезмәт мәгълүматы белән эш тәртибен; хезмәтне саклау, техника куркынычсызлыгы һәм янгыннан саклану нормаларын һәм кагыйдәләрен; муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт башкарганда үз-үзләрен тотуның гомуми принципларына; эшлекле этикет кагыйдәләрен; оргтехника, офис җиһазлары белән эшләү кагыйдәләрен белү;

муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы һәм баш вазифалары буенча – муниципаль хезмәтнең кече һәм өлкән вазифаларына куелган таләпләр, шулай ук җирле үзидарә органы структураларын; тиешле структур подразделение тарафыннан халыкка һәм оешмаларга күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең административ регламентын; Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегенең норматив хокукый актларын әзерләү, килешү һәм кабул итү тәртибен, документлар әйләнеше кагыйдәләрен һәм эш башкару технологиясен (документ алып бару, саклау һәм мәгълүмат алу);

муниципаль хезмәтнең югары вазифалары буенча – муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы һәм баш вазифалары өчен билгеләнгән таләпләр; шулай ук идарә

итүнең, функциональ бурычларның һәм эш стиленең оештыру структураларының төп төрләрен; функциональ бурычларны һәм эш стилен; вазифаи бурычлар андый мәгълүматларны куллану белән бәйле вазифаи бурычларны үтәү белән бәйле булганда дәүләт сере саналган мәгълүматлар белән эшләү тәртибен; эшне оештыруны; персонал белән эшләү нигезләрен; массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү ысулларын һәм формаларын белү;

2. Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен күнекмәләргә (куелган бурычларны хәл итү өчен алган белемнәрне практикада куллана белү, тәҗрибә күнекмә дип аңлашыла) түбәндәге типовой квалификацион таләпләр куела:

муниципаль хезмәтнең кече һәм өлкән вазифалары буенча – компьютер техникасы, оргтехника һәм коммуникация чаралары белән эшли белү; шәхси хезмәтне оештыру һәм эш вакытын планлаштыру; югары стилистик дәрәҗәдә белешмә-мәгълүмати һәм эшлекле, аналитик документлар төзү; эшлекле һәм һөнәри аралашу; заманча мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар белән эшли белә;

муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы һәм баш вазифалары буенча – муниципаль хезмәтнең кече һәм өлкән вазифаларына куелган таләпләр, шулай ук югары стилистик дәрәҗәдә белешмә-мәгълүмати һәм эшлекле, аналитик документларга мөхәррирлек кылу; куелган бурычларны үтәүне тәэмин итү; алга таба идарәчелек карарларын кабул итү өчен тәкъдимнәр эшләү; эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә чаралар уздыру һәм әзерләү; перспективалы һәм агымдагы планнарны башкару; куелган бурычларны үтәүне тәэмин итү; идарәчелек карарларын оператив башкару; җитәкче катнашындагы чараларны оештыруны тәэмин итү;

муниципаль хезмәтнең югары вазифалары буенча – муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы һәм баш вазифалары өчен билгеләнгән таләпләр, шулай ук оештыру-җитәкчелек итү эшчәнлегендә күнекмәләр; идарә итү карарларын оператив кабул итү һәм башкару; куелган бурычларны хәл итүдә планлаштыру, контроль, системалы якын килү; кабул ителгән карарларның нәтиҗәләрен фаразлау һәм анализлау; мәгълүматны анализлау һәм системалаштыру; халык алдында чыгыш ясау; дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештә булу; мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче проблемалы вәзгыятьне үзвакытында ачыклау һәм хәл итү; утырышлар, комиссияләр, эшче төркемнәр һәм башка чараларны әзерләү һәм уздыру буенча эш оештыру; перспектикалы һәм агымдагы планнарны төзү һәм башкару.

3. Мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональлеген һәм компетентлыгын тәэмин итү максатларында бу өлкәдәге белемнәргә һәм күнекмәләргә түбәндәге типовой квалификацион таләпләр билгеләнә:

муниципаль хезмәтнең кече, өлкән һәм әйдәп баручы вазифалары буенча –

аппарат һәм программалы тәэмин ителешне белү; ведомствоара документ әйләнеше мөмкинлекләрен кулллануны кертеп, муниципаль органнарда заманча мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне куллану мөмкинлекләрен һәм үзенчәлекләрен; мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә гомуми мәсьәләләрне; компьютерның эчке һәм перифиреяле җайланмалары, мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләр, шул исәптән, Интернет белән эш күнекмәләре; операцион системада, текстлы редакторда эшләү; электрон почта белән идарә итү; электрон таблицалар белән эшләү; претензияләр әзерләү; электрон документларда график объектларнны куллану; мәгълүматлар базасы белән эшләү;

муниципаль хезмәтнең баш һәм югары вазифалары буенча – муниципаль хезмәтнең кече һәм өлкән вазифалары өчен бигеләнгән таләпләр, шулай ук мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә хокукый аспектларны белү; мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә дәүләт сәясәте приоритетларын һәм программалы документларын; мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып оешмаларга һәм халыкка муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә хокукый аспектларны; проектлы идарә нигезләрен; муниципаль органнарда заманча мәгълүмати технологияләр куллану мөмкинлекләрен һәм үзенчәлекләрен исәпкә алып төркем эшчәнлеге белән идарә итү һәм стратегик планлаштыру күнекмәләрен; проектлар белән идарә итү системалары белән эшләү.

Тиешле муниципаль органнар эшчәнлегендә мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне иңдерү мәсьәләләре белән җитәкчелек итүче вазифаи затлар, информатизация мәсьәләләре карамагында булган подразделение хезмәткәрләре; тиешле муниципаль органда мәгълүмати системаларны үстерү һәм идарә итү, булдыру буенча функцияләр вазифаи бурычларына кергән муниципаль хезмәткәрләрне; тиешле подразделениеләргә йөкләнгән функцияләрне автоматлаштыруны тәэмин итүче, программа продуктларыннан файдаланучы булган подразделение хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белемнәр һәм күнекмәләр исемлеге билгеләнә:

- гражданнар һәм оешмалар белән үзара бәйләнеш системасын; муниципаль хакимият органнарының төп бурычларын һәм функцияләрен үтәргә ярдәмне тәэмин итүче учет системаларын; ведомствоара бәйләнеш системаларын; муниципаль мәгълүмати ресурслар белән идарә итү системасын; мәгълүматларны җыю, эшкәртү, саклау һәм анализлауны тәэмин итүче мәгълүмати-аналитик системаларны; электрон архивлар белән идарә итү системаларын; мәгълүмати куркынычсызлык системаларын; эксплуатация белән идарә итү системаларын белү;

- гражданнар һәм оешмалар белән үзара бәйләнеш системалары белән эш күнекмәләре; ведомствоара бәйләнеш системалары белән эшләр; муниципаль мәгълүмати ресурслар белән идарә итү системалары белән эшләр;мәгълүматларны җыю, эшкәртү, саклау һәм анализлауны тәэмин итүче мәгълүмати-аналитик системалар белән эшләр; электрон архивлар, мәгълүмати

куркынычсызлык, эксплуатация белән идарә итү системалары белән эш күнекмәләре;.

2. муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен түбәндәге типовой квалификацион таләпләр куела:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата:
югары, баш һәм әйдәп баручы вазифалар төркеме өчен - югары белем булу; өлкән һәм кече вазифалар төркеме өчен – югары белем һәм урта һөнәри белем булу;
муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә:
муниципаль хезмәтнең югары вазифалары буенча 2 елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча стаж, 4 елдан ким булмаган – әзерлек юнәлеше буенча;

муниципаль хезмәтнең баш вазифалары буенча – бер елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча эш стажы, ике елдан ким булмаган стаж – әзерлек юнәлеше буенча;

Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы, өлкән һәм кече төркемнәре вазифаларын алмаштыру өчен әзерлек юнәлеше, белгечлек буенча эш стажы яисә муниципаль хезмәт стажына квалификацион таләпләр билгеләнми.

3. Гамәлдәге пунктның максатларында муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында һәм хәрби хезмәтнең һәм башка төрдәге федераль дәүләт хезмәте вазифаларында шуларга тәңгәлләшкән вазифаларда эш стажы исәпләнә.

3.1. Әгәр дә муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясендә муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру өчен кирәк булган әзерлек юнәлешенә, белгечлеккә квалификацион таләпләр күздә тотыла икән, ул чагында белгечлек буенча, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, күрсәтелгән стажга гражданин (муниципаль хезмәткәр) күрсәтелгән белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча белем алу һәм (яисә) квалификация турында документ алганнан соң, бу белгечлек, эш юнәлеше буенча эш чорлары кертелә.

3.2. Әгәр дә муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясендә муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру өчен кирәк булган әзерлек юнәлешенә, белгечлеккә квалификацион таләпләр күздә тотылмый икән, ул чагында гражданинның (муниципаль хезмәткәрнең) белгечлек буенча, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру өчен квалификацион таләпләргә туры килә торган шул дәрәҗәдәге һөнәри белем турында документ алганнан соң, муниципаль хезмәт вазифасы буенча вазифаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган, башкарганда белем һәм күнекмәләр алынган эш чоры күрсәтелгән стажга кертелә.

4. Контракт буенча билгеләнә торган муниципаль районның җирле хакимияте башлыгы вазифасына кандидатларга өстәмә таләп буларак биш елдан ким булмаган идарә итү эшчәнлеге тәҗрибәсе булу билгеләнә. Гамәлдәге өлештә оешма, дәүләт органы, муниципаль орган җитәкчесе, җитәкче урынбасары вазифаларында, шулай ук аларның структур подразделениеләрендә җитәкче вазифаларында эш идарә итү эшчәнлеге дип аңлашыла. Контракт буенча билгеләнә торган җирле хакимият башлыгы вазифасына кандидатларга өстәмә таләпләр “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнергә мөмкин.

5. Бик яхшы билгеләре булган белгеч яисә магистр дипломы булган затлар өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификацион таләпләр диплом бирелгән көннән соң өч ел эчендә билгеләнә – ярты елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча бер ел эш стажы.

9. Муниципаль хезмәткәрләрнең класслы чиннары

1. Класслы чиннар муниципаль хезмәткәрләргә бирелә һәм муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен квалификацион таләпләргә һөнәри әзерлек дәрәҗәсенә туры килүен күрсәтә.

2. Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләргә түбәндәге класслы чиннар бирелә:

муниципаль хезмәтнең югары вазифаларын башкаручыларга - 1, 2 яисә 3нче классллы гамәлдәге муниципаль киңәшче;

муниципаль хезмәтнең баш вазифаларын башкаручыларга - 1, 2 яисә 3нче классллы муниципаль киңәшче;

муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазифаларын башкаручыларга - 1, 2 яисә 3нче классллы муниципаль киңәшче;

муниципаль хезмәтнең өлкән вазифаларын башкаручыларга - 1, 2 яисә 3нче классллы муниципаль хезмәт референты;

муниципаль хезмәтнең кече вазифаларын башкаручыларга - 1, 2 яисә 3нче классллы муниципаль хезмәт сәркатибе;

3. Муниципаль хезмәт вазифаларын югарыда күрсәтелгән төркемнәргә кертү Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазифалары Реестры нигезендә башкарыла.

6. Муниципаль хезмәткәрләргә класслы чиннар бирү һәм муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазифаларына күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән азат иткәндә аларны саклау тәртибе

1. Муниципаль хезмәткәрләргә класслы чиннар алдагы класслы чинда булуның билгеләнгән озынлыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт вазифалары төркеме чикләрендә алмаштырылган вазифа белән муниципаль хезмәт вазифасы нигезендә, эзлеклелек белән бирелә.

2. Класслы чин беренче яисә чираттагы булырга мөмкин.

3.Муниципаль хезмәтнең билгеле бер төркеме вазифасына беренче тапкыр билгеләнә торган муниципаль хезмәткәрләргә 3 нче класслы чин бирелә.

4.Муниципаль хезмәткә федераль дәүләт гражданлык хезмәтенең класслы чины, дипломатик рангы, хәрби яисә махсус званиесе, Татарстан Республикасының яисә Россия Федерациясенең башка субъектының дәүләт гражданлык хезмәтенең класслы чины, муниципаль хезмәтнең квалификацион разряды булган гражданинны эшкә алганда, аңа беренче класслы чин муниципаль хезмәт вазифалары төркеме чикләрендә алмаштыручы вазифа нигезендә бирелә.

5.Муниципаль хезмәткәргә класслы чин билгеләү максатлары өчен, гамәлдәге пунктның 4 нче өлеше нигезендә, муниципаль хезмәтнең квалификацион разрядлары һәм класслы чиннары нисбәте, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазифаларының һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының нисбәте,
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең класслы чиннары һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт гражданлык хезмәте, федераль дәүләт гражданлык хезмәтенең класслы чиннары нисбәте, шулай ук федераль дәүләт гражданлык хезмәтенең, дипломатик рангларның, хәрби һәм махсус званиеләрнең класслы чиннары нисбәте.

6) Әгәр гамәлдәге пунктның 5 өлешендә күздә тотылганча, гамәлдәге пунктның 4 нче өлеше нигезендә бирелә торган квалификацион разрядларның һәм класслы чиннарның, вазифаларның нисбәте муниципаль хезмәткәрнең квалификацион разрядының Россия Федерациясенең башка субъекты яисә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең класслы чинының, хәрби һәм махсус званиесенең, дипломатик рангының, федераль дәүләт гражданлык гражданлык хезмәтенең класслы чиныннан түбән булса, муниципаль хезмәткәргә муниципаль хезмәтнең квалификацион разрядыннан, Россия Федерациясенең башка субъектыннан яисә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең класслы чиныннан, хәрби һәм махсус званиесеннән, дипломатик рангыннан, федераль дәүләт гражданлык хезмәтенең класслы чиныннан түбән булмаган, әмма муниципаль хезмәтнең алмаштырган вазифасына караган муниципаль хезмәтнең вазифалар төркеме чикләрендә, 1 нче

классллы класс чиныннан югары булмаган классллы чин билгеләнә.

Алга таба муниципаль хезмәткәргә чираттагы классллы чин билгеләгәндә аның муниципаль хезмәтнең квалификацион разрядында, Россия Федерациясенең башка субъекты яисә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең классллы чинында, хәрби һәм махсус званиесендә, дипломатик рангында, федераль дәүләт гражданлык хезмәтенең тиешле классллы чинында булу вакыты исәпкә алына.
Муниципаль хезмәткәргә беренче классллы чин сынау уңышлы тәмамланганнан соң билгеләнә, әгәр дә сынау билгеләнмәгән булса, ул чагында муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәткә билгеләнүеннән соң өч айдан да иртә булмаган вакытта билгеләнә.
Муниципаль хезмәтнең 2 һәм 3 нче классллы референтына һәм сәркатибенә класслллы чиннарда булуның минималь срогы бер ел тәшкил итә, 2 һәм 3 нче классллы муниципаль хезмәт киңәшчесенә – ике ел, 2 һәм 3 нче классллы гамәлдәге муниципаль киңәшчегә – бер ел. Сәркатип, референт, муниципаль хезмәт киңәшчесе, муниципаль киңәшчесенә һәм 1 нче классллы гамәлдәге муниципаль киңәшчегә классллы чиннарда булу срогы билгеләнми. Күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләрне классллы чиннарда күтәрү муниципаль хезмәтнең тиешле төркеменең югарыда торган вазифаларына күчерелгәндә мөмкин.

6. Бирелгән классллы чинда булу срогы билгеләнгән көннән башлап исәпләнә башлый. Классллы чин бирелү турында карар кабул ителгән көн классллы чин бирелгән көн булып исәпләнә. Классллы чин квалификацион имтихан нәтиҗәләре буенча билгеләнгән очракта, муниципаль хезмәткәрнең квалификацион имтихан тапшырган көне классллы чин бирелгән көн дип исәпләнә.

7. Муниципаль хезмәткәргә чираттагы классллы чин алдагы классллы чинда муниципаль хезмәт узу өчен билгеләнгән срок тәмамлангач, муниципаль хезмәткәр үз вазифаи бурычларын тиешенчә башкарган һәм муниципаль хезмәткәргә бирелә торган классллы чинга тиң яки югарырак классллы чин каралган муниципаль хезмәт вазифасын алмаштырган очракта бирелә.

8. . Дисциплинар шелтә бирелгән, шулай ук аларга карата хезмәт тикшерүе уздырыла яисә җинаять эше кузгатылган муниципаль хезмәткәрләргә чираттагы классллы чин бирелми.

9. Муниципаль хезмәткәргә классллы чин муниципаль хезмәттә аеруча хезмәтләре өчен бүләкләү чарасы сыйфатында бирелергә мөмкин:
тиешле классллы чинда муниципаль хезмәт узу өчен гамәлдәге пунктның 9 нчы өлешендә билгеләнгән срок тәмамланганчы, ләкин моңа кадәр бирелгән чинда кимендә алты айдан иртәрәк булмаган – муниципаль хезмәт вазифаларының бу төркеменә тәңгәл килүче чираттагы классллы чиннан югары түгел;

алмаштырыла торган вазифа караган муниципаль вазифалары төркемнәре чикләрендә, 3 нче класс классnúmы чины булган муниципаль хезмәткәргә - 1 нче класс, әмма 3 класс классны чинга тәңгәл килүче муниципаль хезмәт узуга гамәлдәге пунктның 9 нчы өлешендә билгеләнгән срок тәмамлангангач, класс чиннарының эзлеклелеген сакламыйча, бер баскычка югары.

10. Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең югарырак вазифасына билгеләгәндә, гамәлдәге пунктның 9 нчы өлешендә билгеләнгән, алдагы классны чинда булу срогы чыккан очракта, вазифаларның элекке төркеме чикләрендә аңа чираттагы классны чин бирелергә мөмкин.

11. Муниципаль хезмәткәрне ул моңа кадәр алмаштырган муниципаль хезмәт вазифаларының югарырак төркеменә караган муниципаль хезмәт вазифасына билгеләгәндә, әгәр дә бу классны чин муниципаль хезмәткәр ия булган классны чиннан югары булса, күрсәтелгән хезмәткәргә гамәлдәге Нигезләмәнең 9 пункты нигезендә муниципаль хезмәт вазифаларының әлеге төркеме өчен беренче классны чин бирелә. Күрсәтелгән очракта классны чин эзлеклелек сакламыйча һәм алдагы классны чинда булу срогын исәпкә алмыйча бирелә.

12. Муниципаль хезмәт вазифаларын вәкаләтләрнең билгеле бер срогына алмаштыручы муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль хезмәт вазифаларының югары төркеменә караган муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыручы муниципаль хезмәткәрләрдән тыш, классны чиннар квалификацион имтихан нәтиҗәләре буенча бирелә. Квалификацион имтихан дәүләт гражданлык хезмәткәрләре квалификацион имтихан бирү өчен билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

13. Муниципаль хезмәткәрләргә классны чиннар муниципаль хезмәткәр җитәкчесенең турыдан-туры гаризасы буенча яллаучының (эш бирүченең) акты белән бирелә.

19. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирелү турында гариза кертү тәртибе һәм аңа беркетелгән документлар исемлеге муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

14. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирелү турында карар, гамәлдәге пунктның 13 нче өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, бер айдан да соңармаган срокта кабул ителергә тиеш:

1) квалификацион имтихан уздырган көннән башлап;

классны чинны квалификацион имтиханнан башка биргәндә вәкаләтле җирле үзидарә органының вазифаи затына яки органына барлык кирәкле документлар белән классны чин бирелү турында гариза кертелгән

көннән.

21. Муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазифаларына күчергәндә, шулай ук муниципаль хезмәттән азат ителгәндә, муниципаль хезмәткәргә бирелгән классны чин саклана. Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазифасына билгеләгәндә, аңа бирелгән чин чираттагы классны чин билгеләнгән тәртиптә бирелгәнче саклана.

22.Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирелү турында мәгълүматлар муниципаль хезмәткәрнең шәхси эш кәгазьләренә һәм хезмәт кенәгәсенә кертелә.

11. Муниципаль хезмәтнең классны чинын саклап калу һәм аннан мәхрүм итү

1. Бирелгән классны чин муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтнең алмаштырган вазифасыннан азат ителгәндә һәм муниципаль хезмәттән азат ителгәндә (шул исәптән, лаеклы ялга чыгу), шулай ук кабаттан муниципаль хезмәткә кергәндә сакланып калына.

2. Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазифасына билгеләгәндә аңа бирелгән классны чин билгеләнгән тәртиптә чираттагы классны чин бирелгәнче сакланып калына.

3. Бирелгән классны чиннан мәхрүм итү федераль законнар нигезендә, суд карары буенча мөмкин.

III. Муниципаль хезмәткәрнең хокукый торышы (статусы)

12. Муниципаль хезмәткәр

1. Җирле бюджет хисабыннан түләнә торган акчалата тулы керем өчен муниципаль хезмәт вазифасы буенча бурычларны Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкаручы гражданин муниципаль хезмәткәр булып санала.

2. Җирле үзидарә органнарының, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренең эшчәнлеген техник тәэмин ителеш буенча вазифалар башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштырмыйлар һәм муниципаль хезмәткәр булып тормыйлар.

13. Муниципаль хезмәткәрнең төп хокуклары

1. Муниципаль хезмәткәрнең хокуклары түбәндәгечә:

1) , хезмәт буенча алга таба күтәрелү шартлары һәм вазифаи бурычларны башкаруның сыйфатын бәя бирү критерийлары, муниципаль хезмәтнең алмаштырган вазифасы буенча аның хокукларын һәм бурычларын

билгеләүче документлар белән танышу;

2) вазифаи бурычларны башкару өчен кирәкле оештыру-техник шартлар белән тәэмин итү;

3) хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турында законнар һәм хезмәт килешүе (контракт) нигезендә хезмәткә түләү һәм башка түләүләр;

3) эш (хезмәт) көненең нормаль озынлыгын билгеләү, ял һәм эш көне саналмаган бәйрәм көннәре, шулай ук ел саен түләүле отпуск белән тәэмин ителә торган ял;

4) вазифаи бурычларны үтәү, шулай ук җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертү өчен кирәкле булган мәгълүматны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә алу;

6) үз инициативаң буенча муниципаль хезмәтнең вакантлы вазифасын алмаштыруга конкурста катнашу;

7) җирле бюджет хисабыннан муниципаль хокукый акт нигезендә өстәмә һөнәри белем алу;

8) үзеңнең персональ мәгълүматларыңны саклау;

9) үз шәхси эш кәгазьләреңнең барлык материаллары, һөнәри эшчәнлек турында бәяләмә һәм шәхси эш кәгазьләренә кертү өчен башка документлар белән танышу, шулай ук аның язма аңлатмаларын шәхси эш кәгазьләренә теркәү;

10) үз хокукларыңны, социаль-икътисадый һәм һөнәри мәнфәгатьләрне яклау өчен һөнәри союзлар булдыру хокукын кертеп, берләшү;

11) хезмәт законнары нигезендә шәхси хезмәт бәхәсләрен карау, муниципаль хезмәттә үз хокукларыңны һәм законлы мәнфәгатьләрне яклау (аларның кимчелекләре буенча судка шикаять бирү);

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия белән тәэмин итү.

3. Муниципаль хезмәткәр, контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасын алмаштыручы муниципаль хезмәткәрдән тыш, яллаучы (эш бирүче) вәкиленең алдан бирелгән язма хәбәре белән башка түләүле эш башкарырга хокуклы, әгәр дә бу мәнфәгатьләр каршылыгына китермәсә һәм “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законда башкача каралмаган булса.

14. Муниципаль хезмәткәрнең төп бурычлары

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә бурычлы:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституцион законнарын, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, муниципаль берәмлек уставын һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

2) вазифаи инструкция нигезендә вазифаи бурычларны үтәргә;

3) вазифаи бурычларны үтәгәндә расага, милләткә, телгә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка торышка карамастан, кешенең һәм гражданинның хокукларын, иреген һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен якларга;

4) җирле үзидарә органында, муниципалҗ берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында билгеләнгән эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен, вазифаи инструкцияне, хезмәт мәгълүмате белән эш тәртибен үтәргә;

5) вазифаи бурычларны тиешенчә үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен тотарга;

6) дәүләтнеке һәм федераль законнар белән яклана торган башка серләрне, шулай ук вазифаи бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә билгеле булган мәгълүматларны, шул исәптән, гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә яисә аның намусына һәм абруена кагылган мәгълүматларны фаш итмәскә;

7) дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән, вазифаи бурычларны үтәү өчен аңа бирелгән мөлкәтне саклау;

8) үзең һәм гаилә әгъзалары турында мәгълүматларны Россия Федерациясе законнары белән каралганча, билгеләнгән тәртиптә тапшырырга;

9) Россия Федерациясе гражданлыгы булудан туктау турында Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан көнне яисә чит дәүләт гражданлыгы алу турында чит дәүләт гражданлыгы алган көнне яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә хәбәр итәргә;

10) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән тыюларны бозмаска, бурычларны үтәргә, чикләүләрне сакларга;

11) мәнфәгатьләр каршылыгына китерү мөмкин булган, вазифаларны башкарганда шәхси кызыксынучанлык турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача формада хәбәр итәргә, һәм мондый каршылыкны булдырмау буенча чаралар күрергә.

2. Муниципаль хезмәткәр үзенә бирелгән хаксыз йөкләмәне үтәргә хокуклы түгел. Тиешле җитәкчедән муниципаль хезмәткәр фикеренчә хаксыз булган йөкләмә алган очракта, әлеге йөкләмәне үтәгәндә бозылырга мөмкин булган федераль законнар нигезләмәләрен һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, муниципаль хокукый актларны күрсәтеп, әлеге йөкләмәнең хаксыз булуы турында язмача формада нигезләүне муниципаль хезмәткәр йөкләмә биргән җитәкчегә тапшырырга тиеш.

Җитәкче әлеге йөкләмәне язмача формада раслаган очракта, муниципаль хезмәткәр аны үтәүдән баш тартырга бурычлы. Хаксыз йөкләмәне үтәгән очракта, муниципаль хезмәткәр һәм әлеге йөкләмәне биргән җитәкче Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тоталар.

15. Муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр

1. Түбәндәге очракта гражданин муниципаль хезмәткә, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттә була алмый:

1) законлы көченә кергән суд карары белән хезмәткә яраксыз һәм чикләнгән хезмәткә яраксыз дип табылганда;

2) законлы көченә кергән, суд карары буенча аның муниципаль хезмәт вазифасы буенча вазифаи бурычларны үтәү мөмкинлеген төшереп калдыручы җәзага тартылуы;

3) әгәр гражданин алмаштырырга дәгъва итүче яисә муниципаль хезмәткәр алмаштыра торган муниципаль хезмәт вазифасы андый мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булса, федераль законнар белән саклана торган дәүләти һәм башка серләр булып саналган мәгълүматларга керү процедурасын узудан баш тартканда;

4) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль закон нигезендә медицина оешмасы бәяләмәсе белән расланган һәм аны узуга яисә муниципаль хезмәткә керүгә каршылык тудыручы авыруларның булуы;

5)җирле хакимиятне җитәкли торган муниципаль берәмлек башлыгы белән якын туган яисә үзлекләр булу (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абый-апа, эне-сеңел, шулай ук ир белән хатынның балалары һәм балаларның ир белән хатыны), әгәр муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру әлеге вазифаи затның турыдан-туры буйсынуында яисә әлеге вазифаи зат контролендә булса, әгәр муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру турыдан-туры буйсыну яисә берсенең икенчесе контролендә булуы белән бәйле булса;

6)аның нигезендә чит ил гражданины муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, Россия Федерациясенең халыкара килешүендә катнашучы – чит дәүләт гражданлыгын туктату, аның нигезендә Россия Федерациясе гражданины чит дәүләт гражданлыгы булган муниципаль хезмәттә булырга хокукы булган, Россия Федерациясенең халыкара килешүендә катнашучы булмаган чит дәүләт территориясендә Россия

Федерациясе гражданинының даими яшәү хокукын раслаучы яшәүгә хокук яисә башка документ алу яисә аның чит дәүләт гражданлыгын алуы;

7) чит дәүләт гражданлыгы булуы, аның нигезендә чит ил гражданинының муниципаль хезмәттә булырга хокукы булган, Россия Федерациясенең халыкара килешүендә катнашучы – муниципаль хезмәткәр чит дәүләт (чит дәүләтләр) гражданины булган очраклардан тыш;

8) муниципаль хезмәткә кергәндә ялган документлар яисә белә торып ялган документлар тапшыру;

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль закон, 25.12.2008 елдагы “Коррупциягә каршы тору турында”гы №273-ФЗ Федераль законнары (алга таба – “Коррупциягә каршы тору турында Федераль закон) һәм башка федераль законнар нигезендә муниципаль хезмәткә кергәндә тулы булмаган мәгълүматлар яисә белә торып ялган мәгълүматлар тапшыру;

9) гамәлдәге Нигезләмәнең 18.1 пунктында каралган мәгълүматларны тапшырмау;

10) законлы нигезсез чакырылыш буенча хәрби хезмәт узмаган дип тану – Россия Федерациясенең тиешле субъектының чакырылыш комиссиясенә күрсәтелгән гаризага шикаять белдерү өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 10 ел дәвамында, әгәр күрсәтелгән гариза һәм (яки) Россия Федерациясенең тиешле субъектының чакырылыш комиссиясе карары гражданинның шикаяте буенча күрсәтелгән гариза судта тикшерелсә – күрсәтелгән гаризага гражданинның шикаяте буенча Россия Федерациясенең тиешле субъектының чакырылыш комиссиясе карары һәм (яки) күрсәтелгән нәтиҗә чыгарганда гражданинның хокуклары бозылмаган дип танылган суд карары законлы көченә кергән көннән 10 ел дәвамында.

2. Муниципаль берәмлек башлыгы белән якын туганнар (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абый-апа, эне-сеңел, шулай ук ир белән хатынның балалары һәм балаларның ир белән хатыны) булган очракта, гражданин җирле хакимият башлыгы вазифасына, ә муниципаль хезмәткәр контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасын алмаштыра алмый.

3. Гражданин муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру өчен билгеләнгән яшь чиген – 65 яшь тулганнан соң муниципаль хезмәткә алына алмый.

16. Муниципаль хезмәт белән бәйле тыюлар

1. Муниципаль хезмәт узу белән бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр тыела:

1) мондый очракларда муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру:

а) Россия Федерациясенең дәүләт вазифасына яисә Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазифасына сайлану яки билгеләнү, шулай ук дәүләт хезмәте вазифасына билгеләнгән очракта;

б) муниципаль вазифага сайланганда яки билгеләнгәндә;

в) профсоюз союзы органында түләүле сайлау вазифасына, шул исәптән, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, җирле үзидарә органында булдырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлау органына сайланганда;

2) шәхсән һәм ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эше белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы идарәсендә яисә коммерциягә бәйле булмаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдән, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез милек хуҗаларының ширкәтенең гомуми җыелышында катнашырга, аерым башкарма орган сыйфатында күрсәтелгән коммерциягә бәйле булмаган оешмалар (сәяси партиялдән тыш) белән идарә итүдә бушлай нигездә катнашырга яисә муниципаль берәмлеккә караган учредитель (акционер, катнашучы) тарафыннан идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләренең бушлай нигездә күрсәтелүеннән тыш, (муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучының вәкиле (эш бирүче) рөхсәтеннән идарәнең коллегиаль органнарының составына федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш, муниципаль хосусыйлыкта булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү яки оешма учредителе вәкаләтләренең муниципаль берәмлек исеменнән башкарылу тәртибен билгеләүче муниципаль актлар нигезендә керү;

3) федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш, муниципаль хосусыйлыкта булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре белән) идарә итү яки оешма учредителе вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән башкару тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә;

федераль законнарда башкача каралмаган очракта, муниципаль хезмәт вазифасын башкарган яисә аңа турыдан-туры буйсынган яисә контролендә булган муниципал берәмлекнең сайлау комиссиясенең, җирле үзидарә органында өченче затларның эшләре буенча ышанычлы зат яисә вәкил булырга;

4) вазифаи урын биләү яисә вазифаи бурычларны үтәү белән бәйле рәвештә, физик һәм юридик затлардан бүләкләүләр (бүләк, акчалата бүләк, ссуда, хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һ.б. бүләкләүләр) алырга. Россия Федерациясенең Гражданлык кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрнең беркетмәле

чаралар, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләкләре, муниципаль хосусыйлык дип таныла һәм ул муниципаль вазифа башкара торган муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә, җирле үзидарә органына муниципаль хезмәткәр тарафыннан акт буенча тапшырыла. Беркетмәле чара, хезмәт командировкасы яисә башка рәсми чара белән бәйле рәвештә алынган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә аны сатып ала ала;

5) физик һәм юридик затлар хисабыннан командировкаларга чыгу, муниципаль берәмлекнең башка сайлау комиссияләре, җирле үзидарә органнары, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссияләре, шулай ук халыкара һәм чит илнең коммерциягә бәйле булмаган оешмалары, чит дәүләтләрнең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары белән җирле үзидарә органының ышаныч язуы буенча ике яклы нигездә башкарыла торган командировкалардан тыш;

6) матди-техник, финанс һәм башка тәэмин ителеш чараларыннан, башка муниципаль мөлкәттән вазифаи бурычларны үтәү белән бәйле булмаган максатларда файдалану;

7) федераль законнар нигезендә конфиденциаль мәгълүмат саналган мәгълүматларны яисә вазифаи бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә аңа билгеле булган хезмәт мәгълүматын фаш итәргә һәм муниципаль хезмәт белән бәйле булмаган максатларда файдаланырга;

8) җирле үзидарә органнары, муниципаль берәмлекнең һәм аның җитәкчеләренең сайлау комиссиясе, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә карата ачык әйтергә, бәя бирергә, шелтә белдерергә (шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында), әгәр дә ул аның вазифаи бурычларына кермәсә;

9) муниципаль берәмлек башлыгының язмача рөхсәтеннән башка чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәннидән кала) кабул итәргә, әгәр күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара ярдәмләшү аның вазифаларына керсә;

10) сайлау алды агитациясе, шулай ук референдум мәсьәләләре буенча агитация өчен
вазифаи торышның өстенлекләреннән файдаланырга,

10) вазифаи торышны сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый

берләшмәләр мәнфәгатьләрендә файдаланырга, шулай ук муниципаль хезмәткәр сыйфатында күрсәтелгән берләшмәләргә үз мөнәсәбәтеңне ачыктан-ачык белдерергә;

12) җирле үзидарә органнарында, башка муниципаль органнарда сәяси партияләр структураларын, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр булдыру яисә күрсәтелгән структуралар булдыруга ярдәм итәргә (һөнәри союзлар, шулай ук иҗтимагый үзешчәнлекнең ветераннар һәм башка органнарыннан башка);

13) хезмәттәге бәхәсләрне җайга салу максатларында вазифаи бурычларны башкаруны туктатырга;

14) Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган идарә органнары, попечительлек яисә күзәтчелек советлары, чит илләрнең коммерциягә бәйле булмаган дәүләтнеке булмаган оешмалары һәм аларның структур подразделениеләре составына керергә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкача каралмаган булса;

15) яллаучы вәкиленең (эш бирүче) язмача рөхсәтеннән башка чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар хисабыннан махсус рәвештә финанслана торган түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкача каралмаган булса;

2. Контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасын башкаручы муниципаль хезмәткәр белем бирү, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы түгел. Шул ук вакытта белем бирү, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек өчен финанслау бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар хисабыннан гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкача каралмаган булса;

3.Контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасын алмаштыручы муниципаль хезмәткәр идарә органнарына, попечительлек һәм күзәтчелек органнарына, коммерциягә бәйле булмаган, дәүләтнеке булмаган оешмалар һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган структур подразделениеләре составына керергә хокуклы түгел, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкача каралмаган булса;

4.Муниципаль хезмәттән азат ителгән гражданин вазифаи бурычларны башкару белән бәйле рәвештә билгеле булган конфиденциаль характердагы мәгълүматларны яисә хезмәт мәгълүматын физик зат яисә оешма мәнфәгатьләрендә файдаланырга яисә фаш итәргә хокуклы түгел.

5. Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән

вазифалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазифасын алмаштырган гражданин, муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң ике ел дәвамында федераль законнарда каралган очракларда гражданлык-хокукый килешү шартларында әлеге оешмада эш башкарырга һәм (яисә) хезмәт килешүе шартларында оешмада вазифалар башкарырга хокуклы түгел, әгәр Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган тәртиптә, муниципаль хезмәткәрләрнең эш урынында үз-үзләрен тоту кагыйдәләренә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрне үтәү буенча тиешле комиссия ризалыгыннан башка әлеге оешма белән муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре муниципаль хезмәткәрнең вазифаи бурычларына кергән булса.

17. Муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу

1.Гамәлдәге Нигезләмә максатлары өчен “Коррупциягә каршы тору турында”гы Федераль законның 10 маддәсе, 1 өлешендә билгеләнгәнчә, “мәнфәгатьләр каршылыгы” төшенчәсе кулланыла.

2. Гамәлдәге Нигезләмә максатлары өчен “Коррупциягә каршы тору турында”гы Федераль законның 10 маддәсе, 2 өлешендә билгеләнгәнчә, “шәхси кызыксынучанлык” төшенчәсе кулланыла.

3. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу мәнфәгатьләр каршылыгы ягы булган муниципаль хезмәткәрнең вазифаи һәм хезмәт торышыны үзгәртүдә торырга мөмкин, хәтта билгеләнгән тәртиптә вазифаи (хезмәт) бурычларын башкарудан читләштерүгә һәм мәнфәгатьләр каршылыгы килеп тууга сәбәп булган файдадан баш тартуга кадәр.

4. Әгәр муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы затның кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав капиталында айлар, катнашу өлешләре) тотуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки андый куркыныч туа икән, күрсәтелгән зат Россия Федерациясенең гражданлык законнары нигезендә ышаныч идарәсенә үзенең кыйммәтле кәгазьләрен (оешмаларның устав капиталында айлар, катнашу өлешләре) тапшырырга бурычлы.

5. Мәнфәгатьләр каршылыгы ягы булган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрмәве муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерүче хокук бозу булып тора.

5. Муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык турында билгеле булган яллаучының вәкиле (эш бирүче) муниципаль хезмәтнең башкарган вазифасыннан бөтен вакытка читләштерү вакытына акчалата тәэмин ителешне саклап, каршылыкны җайга салу чорына муниципаль

хезмәтнең башкарган вазифасыннан муниципаль хезмәткәрне читләштерүгә кадәр мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә бурычлы.

7. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар, мәнфәгатьләр каршылыгына китерә һәм китерү мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык аның кул астында эшләүче муниципаль хезмәткәрдә килеп чыгуы турында билгеле булган яллаучы вәкиле (эш бирүче) булган муниципаль хезмәткәрнең чара күрмәве яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерүче хокук бозу булып тора.

8. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәттә үз-үзеңне тотуның гомуми принципларын һәм муниципаль хокукый акт һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы белән билгеләнгән тәртиптә, җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу өчен муниципаль хезмәткәрнең  хезмәттә үз-үзен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр (алга таба – комиссия) төзелергә мөмкин.

9. Комиссия җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе нең хокукый акты белән даими булмаган нигездә формалаштырыла. Комиссиянең сан һәм персональ составы, сроклары һәм аның эш тәртибе күрсәтелгән акт белән билгеләнә.

10. Комиссия составына яллаучының (эш бирүченең) һәм (яки) аларга вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләр , шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр сыйфатында персональ мәгълүматларын күрсәтмичә чакырыл торган фәнни, белем бирү һәм башка оешмалар вәкилләре кертелә. Бәйсез экспертлар саны Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлеше булырга тиеш.

11. Комиссия составы Комиссия кабул итә торган карарларга тәэсир итә алырдай мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге булмаслык итеп формалаштырыла.

17.1. Муниципаль хезмәткәрнең эш урынында үз-үзен тотуына таләпләр

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә бурычлы:

1) вазифаи бурычларын намус белән, югары һөнәри дәрәҗәдә башкарырга;

2) барлык физик һәм юридик затларга һәм оешмаларга карата тигез, гадел мөнәсәбәт тәэмин итәргә, нинди дә булса иҗтимагый һәм дини оешмаларга, һөнәри һәм социаль төркемнәргә, гражданнарга һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә һәм андый берләшмәләргә, төркемнәргә, оешмаларга һәм гражданнарга карата алдан фактлар белән расланмаган дәлилләр китермәскә;

2) вазифаи бурычларны намус белән башкаруга киртә булучы, нинди дә булса шәхси, мөлкәти( финанс) һәм башка мәнфәгатьләр тәэсире белән бәйле гамәлләр кылмаска;

4) сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр һәм башка оешмаларның карарларының үз һөнәри эшчәнлегенә тәэсир итү мөмкинлеген төшереп калдыручы нейтральлек сакларга;

5) гражданнар белән аралашканда үзен нәзакәтле тотарга;

6) Россия Федерациясе халыкларының әхлакый гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә хөрмәт күрсәтү;

7) төрле этник һәм социаль төркемнәр, шулай ук конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алу;

8) милләтара һәм конфессияара килешүгә ярдәм итү;

9) муниципаль органның репутациясенә һәм абруена зыян китерергә мөмкин булган каршылыклы вәзгыятьне булдырмаска.

2.Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр, муниципаль хезмәткәрнең сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегендә катнашуга мәҗбүр итүне булдырмаска бурычлы.

### 18. Керемнәр һәм чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы бурычлар турында мәгълүматлар тапшыру

1. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазифаларын башкарырга дәгъва итүче гражданнар, күрсәтелгән вазифаларны башкаручы муниципаль хезмәткәрләр ялллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы бурычлары, шулай ук тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы бурычлары турында мәгълүмат тапшырырга тиеш. Күрсәтелгән мәгълүматлар Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы бурычлары турында мәгълүматларны тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада тапшырыла.

2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы муниципаль хезмәткәр Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы бурычлары турында мәгълүматларны тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада үз чыгымнары, шулай ук тормыш иптәшенең балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар тапшырырга бурычлы.

3. Муниципаль хезмәткәрнең чыгымнарының, аның тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының тәңгәллегенә контроль “Коррупциягә каршы

тору” һәм 03.12.2012 елдагы “Дәүләт вазифаларын башкаручының һәм башка затларның керемнәренең тәңгәллегенә контроль турында”гы N 230-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары нигезендә башкарыла.

4. Муниципаль хезмәткәр гамәлдәге пункт нигезендә тапшыра торган керемнәр һәм чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы бурычлар турында мәгълүматлар конфиденциаль характердагы мәгълүмат булып торалар, әгәр дә федераль законнар белән дәүләт һәм башка федераль законнар белән саклана торган сер булып саналмаса.

5. Керемнәр һәм чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы бурычлар турында мәгълүматларларны муниципаль хезмәткәрнең, аның тормыш иптәше һәм балигъ булмаган балаларының түләргә сәләтен билгеләү яисә ачыклау өчен, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләрнең, башка оешмаларның, шулай ук физик затларның фондына туры һәм туры булмаган формада иганә җыю өчен куллунырга ярамый.

6. Керемнәр һәм чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы бурычлар турында мәгълүматларларны фаш итүдә һәм Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда әлеге мәгълүматлардан файдалануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тоталар.

7. Муниципаль хезмәткәрнең үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы бурычлары, шулай ук тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыру мәҗбүри булган очракта, яисә белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып санала.
8. 8. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга дәгъва итүче гражданнар тапшыра торган керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, күрсәтелгән вазифаларны башкаручы муниципаль хезмәткәрләр тапшыра торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, Россия Федерациясенең муниципаль хокукый актлары нигезендә муниципаль хезмәткә кергәндә гражданнар тапшыра торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткәрләрнең торган тәртиптә башкарыла торган, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары һәм “Коррупциягә каршы тору турында”гы Федераль закон белән билгеләнгән бурычларны үтәвен, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу турында яисә чикләүләр һәм тыюлар, таләпләр турында үтәлешен тикшерү Татарстан Республикасы Президентының норматив

хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

9. Закон белән саклана торган банк, салым һәм башка серләрне эченә алган мәгълүматларны тапшыру турында рәсми мөрәҗәгатьләр, тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга дәгъва итүче гражданнарга, әлеге вазифаларны башкаручы муниципаль хезмәткәрләрнең, андый гражданнарның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең тормыш иптәше һәм балигъ булмаган балаларына карата оператив-тикшерү чараларын уздыру турында хокук саклау органнарына рәсми мөрәҗәгатьләр муниципаль органнар мәнфәгатьләрендә, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан җибәрелә.

10. Контракт буенча Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын алмаштыруга дәгъва итүче гражданнар һәм күрсәтелгән вазифаны башкаручы зат үз керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматларны, шулай ук тормыш иптәшләре һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматларны Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының югары Президентына тапшыралар.

11. Контракт буенча Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын алмаштыручы зат тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияле челтәрендә урнаштырыла.

Гамәлдәге маддәнең 10 өлеше нигезендә тапшырылган керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты карары буенча башкарыла.

12.. Гамәлдәге маддәнең 10 өлеше нигезендә башкарылган тикшерү нәтиҗәсендә контракт буенча Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын алмаштыручы затның 2013 елның 7 маендагы “Чит илнең финанс интрументларына ия булырга һәм файдаланырга, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында реаль акчалар һәм байлыклар сакларга, счетлар (кертемнәр) ачуны аерым категориягә керүче затларга тыю турында”гы №79-ФЗ Федераль законы, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазифаларын башкаручы һәм башка затларның чыгымнарының һәм

аларның керемнәренең тәңгәллеген контрольдә тоту турында”гы №230-ФЗ Федераль законы, гамәлдәге Федераль законы белән билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты контракт буенча Минзәлә муниципаль районы башлыгы вазифасын алмаштыручы затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына аңа карата башка дисциплинар җәза куллану турында гариза белән, яки судка мөрәҗәгать итә.

13. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы затларның, шулай ук аларның тормыш иптәшләренең һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын контрольдә тотуны башкаручы Татарстан Республикасының дәүләт органы (коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы дәүләт органы подразделениесе яисә күрсәтелгән органның җаваплы заты) Татарстан Республикасы Президентның норматив хокукый акты белән билгеләнә.

### 18.1. “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияле челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында хәбәр итү

1. Муниципаль хезмәткәр, муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга дәгъва кылучы гражданин һәркем алырлык мәгълүмат урнаштырган, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеге бирүче мәгълүматларны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияле челтәрендә сайтлар битләрен һәм (яки) сайт адреслары турында яллаучы вәкиленә түбәндәгеләрне тапшыралар:

1) муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыргуа дәгъва итүче гражданин – хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәткә кергәнче элекке өч календарь ел өчен;

2) муниципаль хезмәткәр – күрсәтелгән мәгълүматны тапшырган елдан элекке календарь ел өчен ел саен, муниципаль хезмәткәрнең вазифаи бурычларын үтәү кысаларында һәркем алырлык мәгълүмат урнаштырган очраклардан тыш.

2.Гамәлдәге пунктның 1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматлар муниципаль хезмәткә кергәндә, муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга дәгъва итүче гражданнар тарафыннан, ә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан – отчет елыннан соң килүче елның 1 апреленнән соңармыйча тапшырыла. Гамәлдәге пунктның 1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән форма буенча тапшырыла.

2. Яллаучы вәкиле карары белән аңа вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләр “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга дәгъва итүчеләр урнаштырган һәркем алырлык мәгълүматны эшкәртүне, шулай ук гамәлдәге пунктның 1 өлешендә каралган мәгълүматларның дөреслеге һәм тулылыгын тикшерүне башкаралар.

## IV. Муниципаль хезмәткә керү, аны узу һәм туктату тәртибе

### 19. Муниципаль хезмәткә керү

1. Муниципаль хезмәткә 18 яше тулган, Россия Федерациясенең дәүләт телен белүче һәм “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законы һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт вазифаларын башкару өчен муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә билгеләнгән квалификацион таләпләргә тәңгәл килүче, муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр сыйфатында “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законның 13 маддәсендә күрсәтелгән шартлар булмаганда.

2)Муниципаль хезмәткә кергәндә, шулай ук аны узганда җенес, раса, милләт, килеп чыгышы, мөлкәти һәм вазифаи торышы, яшәү урыны, дингә мөнәсәбәте, инанулары, иҗтимагый берләшмәләрдә торуына бәйле рәвештә нинди дә булса турыдан-туры яисә өстәмә чикләүләр билгеләү, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатлары белән бәйле булмаган башка шартлар кую мөмкин түгел.

3. Муниципаль хезмәткә кергәндә гражданин түбәндәгеләрне тапшыра:

1) муниципаль хезмәткә керү турында һәм муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру турында үтенеч белән гариза;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкиле, башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;
3) паспорт;

4) хезмәт кенәгәсен, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

5) белем турында документ;

6) мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

7)физик затның Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында учетка куелуы турында таныклык;

8) хәрби учет документлары – запаста булган һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар өчен;
9) муниципаль хезмәткә керүгә каршылык тудыручы авыру булмау турында медицина оешмасы йомгагы;
10) муниципаль хезмәткә кергән елдан элекке ел керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы бурычлары турында мәгълүматлар;

10.1) гамәлдәге Нигезләмәнең 18.1 пунктында каралган мәгълүматлар;

2) федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты фәрманнары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карaралары белән күздә тотылган башка документлар.

3. “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль закон, гражданин муниципаль хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасының Кодексы нигезендә тапшырылган мәгълүматлар федераль законнар билгеләгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин. Аерым муниципаль берәмлекләрдә федераль законнар белән гражданин муниципаль хезмәткә кергәндә тапшырыла торган мәгълүматларны тикшерүгә карата өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.

5. Гамәлдәге пунктның 4 өлешендә каралганча, тикшерү барышында гражданинның муниципаль хезмәткә керүенә каршылык тудыручы шартлар билгеләнгән очракта, күрсәтелгән гражданин муниципаль хезмәткә керүгә каршы килү сәбәпләре турында язмача формада мәгълүмат ала.

6. Гражданинның муниципаль хезмәткә керүе “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, хезмәт законнары нигезендә хезмәт килешүе шартларында муниципаль хезмәт вазифасына билгеләү нәтиҗәсендә башкарыла.

7. Күрсәтелгән вазифаны алмаштыруга конкурс нәтиҗәләре буенча җирле хакимият башлыгы вазифасына керүче гражданин контракт төзи. Контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасын алмаштыру һәм контракт буенча әлеге вазифага билгеләнгән зат белән контрактны төзү һәм өзү тәртибе 06.10.2003 елдагы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплры турында”гы №131-ФЗ Федераль законы белән билгеләнә. Контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасына билгеләнүче зат белән контрактның типовой формасы гамәлдәге Нигезләмәгә Кушымта №2 белән билгеләнгән.

8. Гражданинның муниципаль хезмәт вазифасына билгеләнүе муниципаль хезмәт вазифасына билгеләнү турында яллаучы вәкиле (эш бирүче) акты белән рәсмиләштерелә.

9. Яллаучының вәкиле (эш бирүче) һәм муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәткә кергәндә хезмәт килешүенең яклары булып тора.

10. Муниципаль хезмәт вазифасына билгеләнгәннән соң муниципаль хезмәткәргә хезмәт таныклыгы бирелә. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт таныклыгы формасы һәм тапшыру тәртибе муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан раслана.

20. Муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга конкурс

1. Муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазифасын алмаштырганда хезмәт килешүе төзү алдыннан муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга дәгъва итүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсенә бәя бирү, аларның муниципаль хезмәт вазифасына билгеләнгән квалификацион таләпләргә туры килүен башкаручы конкурс уздырылырга мөмкин.

2.Муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга конкурс уздыру тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы кабул иткән муниципаль хокукый акт белән билгеләнә. Конкурс уздыру тәртибе конкурс уздырган көннән башлап, 20 көннән соңармыйча, аның шартларын, датасы турында мәгълүматларын, уздыру вакытын һәм урынын, шулай ук хезмәт килешүе проектының басылуын күздә тотарга мөмкин. Муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны һәм аны формалаштыру тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы белән билгеләнә. Шәһәр округында, җирлектә урнашкан, авыл торак пукнтларында җирле хакимиятнең вәкаләтләре өлешен башкару йөкләнгән җирле хакимиятнең территориаль органының җитәкчесе вазифасын алмаштыруга конкурс уздырылган очракта, муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясен формалаштыру тәртибе әлеге авыл торак пунктларының һәркайсында гражданнар җыены белән сайланган кандидатуралар әгъзалары санына кертүне күздә тотарга тиеш.

3. Яллаучының вәкиле (эш бирүче) хезмәт килешүе төзи һәм муниципаль хезмәт вазифасына муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе сайлап алган кандидатларның берсен билгели.

21. Муниципаль хезмәткәрләрнең аттестация узуы

1. Муниципаль хезмәткәргә аттестация аның муниципаль хезмәттә башкарган вазифасына тәңгәллеген ачыклау өчен уздырыла. Муниципаль хезмәткәргә аттестация өч елга бер тапкыр уздырыла.

2. Түбәндәге муниципаль хезмәткәрләргә аттестация узу таләп ителми:

1) бер елдан кимрәк вакыт муниципаль хезмәттә булучылар;

2) 60 яше тулганнар;

3) йөкле хатыннар;

4) йөклелек һәм бала табу буенча яисә өч яше тулганчы бала тәрбияләү ялында булучылар. Мондый муниципаль хезмәткәрләргә аттестация ул отпусктан чыгып, бер ел узгач мөмкин.;

5) хезмәт килешүе (контракт) нигезендә муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручылар.

3. Атттестация комиссиясе муниципаль хезмәткәрнең аттестация нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрнең башкарган вазифасына туры килүе яки туры килмәве турында карар чыгара. Аттестация комиссиясе аерым муниципаль хезмәткәрләргә эштә ирешкән уңышлары өчен бүләкләү, шул исәптән, вазифаларын күтәрү, ә кирәк булган очракта, аттестация узучы муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлеген яхшырту турында рекомендацияләр бирергә мөмкин. Аттестация нәтиҗәләре тавыш бирү нәтиҗәләре чыгарылганнан соң муниципаль хезмәткәргә турыдан-туры хәбәр ителә. Атттестация материллары яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) тапшырыла.

4. Аттестация нәтиҗәләре буенча яллаучы вәкиле (эш бирүче) эштә ирешкән уңышлары өчен аерым муниципаль хезмәткәрләрне бүләкләү яки аттестация узган көннән бер айдан соңармыйча муниципаль хезмәткәрне аның ризалыгы белән вазифада түбәнәйтү турында карар кабул итә. Аттестация комиссиясе аттестация нәтиҗәләре буенча аерым муниципаль хезмәткәрләрне өстәмә һөнәри белем алу өчен юнәлтү турында рекомендацияләр бирергә мөмкин.

5. Муниципаль хезмәткәр вазифада түбәнәюе яисә аның ризалыгы белән муниципаль хезмәтнең башка вазифасына күчерү мөмкинлеге булмавы белән килешмәгән очракта, ялллаучы вәкиле (эш бирүче) аттестация нәтиҗәләре белән расланган, җитәрлек квалификациясе булмау нәтиҗәсендә башкарган вазифасына тәңгәл килмәвенә бәйле рәвештә, аттестация узган көннән соң бер ай эчендә аны муниципаль хезмәттән азат итә ала. Әлеге срок чыкканнан соң муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү яисә әлеге аттестация нәтиҗәләре буенча аның вазифасын түбәнәйтү рөхсәт ителми.

6. Муниципаль хезмәткәр аттестация нәтиҗәләренә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

7. Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация уздыру турында нигезләмә Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә аттестация уздыру турында типовой нигезләмәгә тәңгәл рәвештә муниципаль хокукый акт белән раслана.

22. Муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясе

1. Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге җирле үзидарә органы җитәкчесе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе яисә муниципаль хокукый акт белән вәкаләтле булган башка вазифаи зат тарафыннан

расланган вазифаи инструкция нигезендә башкарыла.

2. Муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясенә түбәндәгеләр керә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә, вазифаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белем һәм күнекмәләргә, шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә, белгечлеккә квалификацион таләпләрнең тәңгәл килүе таләп ителгән муниципаль хезмәтнең тиешле вазифасын алмаштыру өчен яллаучының вәкиле (эш бирүченең) карары булган очракта – әзерлек юнәлешенә квалификацион таләпләр;

3) җирле үзидарә эшчәнлеген, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты, җирле үзидарә органының структур подразделениесенең бурычлары һәм фнукцияләре, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратының һәм анда муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыручы функциональ үзенчәлекләрне җайга салучы акт нигезендә, муниципаль хезмәткәрнең вазифаи бурычларны үтәмәве (тиешенчә үтәмәве) өчен җаваплылыгы, хокуклары, вазифаи бурычлары;

муниципаль хезмәткәр идарәчелек һәм башка карарларны мөстәкыйль кабул итәргә яисә хокуклы булган сораулар исемлеге;

4) норматив хокукый актлар һәм (яисә) идарә итү һәм башка карарларның проектларын әзерләгәндә муниципаль хезмәткәр катнашырга хокуклы яисә бурычлы булган сораулар исемлеге;

5) муниципаль хезмәтнең башкара торган вазифасы буенча карар проектларын кабул итү һәм килешү тәртибе;

6) муниципаль хезмәткәрнең вазифаи бурычларны башкару белән бәйле рәвештә җирле үзидарәнең шул ук органының муниципаль органының муниципаль хезмәткәрләре, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты, башка җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, гражданнар һәм оешмалар белән үзара бәйләнеше процедуралары.

3. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазифасын алмаштыруга конкурс, аттестация уздырганда, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеген планлаштырганда вазифаи инструкция нигезләмәләре исәпкә алына.

4. Муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясен башкару нәтиҗәләре муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга конкурс уздырганда яисә муниципаль хезмәткәрне кадрлар резервына керткәндә, аттестация уздырганда аның һөнәри хезмәт эшчәнлегенә бәя биргәндә яисә муниципаль хезмәткәрне бүләкләгәндә исәпкә алына.

23. Муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүен өзү өчен нигезләр

1. Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралганча хезмәт килешүен өзү өчен нигезләрдән тыш, муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүе яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) инициативасы буенча түбәндәге очракларда өзелергә мөмкин:

1) муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру өчен яшь чиге җиткәндә;

3) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, Россия Федерациясенең халыкара килешүе катнашучысы – чит ил дәүләте гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит ил гражданины муниципаль хезмәттә булырга, чит дәүләт гражданлыгы алырга яисә яшәү өчен рөхсәт алырга яисә чит дәүләт гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданины муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган Россия Федерациясенең халыкара килешүе катнашучысы булмаган чит дәүләт территориясендә Россия Федерациясе гражданинының даими яшәвенә хокукны раслаучы башка документ нигезендә;

3) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законның 13, 14, 14.1 һәм 15 маддәләрендә билгеләнгән һәм муниципаль хезмәт белән бәйле тыюлар һәм чикләүләрне үтәмәү;

4) дисквалификация рәвешендә административ җәза куллану.

2.Муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру өчен билгеләнгән тиешле чиккә җиткән муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәттә булу срогын озынайту мөмкин. Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттә калдыру срогын бер тапкыр озынайту бер елдан артык була алмый.

## V. Эш (хезмәт) вакыты һәм ял вакыты

### 24. Эш (хезмәт) вакыты

Муниципаль хезмәткәрләрнең эш (хезмәт вакыты) хезмәт законнары нигезендә җайга салына.

### 25. Муниципаль хезмәткәрнең отпуск ялы

1. Муниципаль хезмәткәргә муниципаль хезмәтнең башкарган вазифасын һәм күләме уртача хезмәт хакын исәпләү өчен хезмәт законнары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган акчалата түләвен саклап еллык отпуск бирелә.

2. Муниципаль хезмәткәрнең еллык түләүле отпускы төп түләүле отпусктан һәм өстәмә түләүле отпусклардан тора.

3. Еллык түләүле төп отпуск муниципаль хезмәткәргә 30 календарь көн озынлыгында бирелә.

4. Муниципаль хезмәткәргә еллык түләүле өстәмә отпусклар тиешле елларны хезмәт иткән өчен (10 календарь көннән артырга тиеш түгел), шулай ук Россия Федерациясенең федераль законнары һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда бирелә.

5. Муниципаль хезмәткәргә тиешле елларны хезмәт иткән өчен еллык өстәмә түләүле отпуск бирү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасының 25.06.2013 №50-ЗРТ муниципаль хезмәт турындагы Кодексы белән билгеләнә.

5.1. Нормаланмаган эш көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә өч календарь көн озынлыгында нормаланмаган эш көне өчен түләүле отпуск бирелә.

6. Муниципаль хезмәткәргә аның язмача гаризасы буенча яллаучы вәкиленең (эш бирүче) карары белән бер елдан артмаган акча түләнмәгән ял бирелергә мөмкин.

7. Муниципаль хезмәткәргә федераль законнарда каралган очракларда акча түләмичә отпуск бирелә.

## VI. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәтенә түләү, муниципаль хезмәткәргә бирелә торган гарантияләр, муниципаль хезмәт стажы

### 26. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәтенә түләү

1. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәтенә түләү ул башкарган муниципаль хезмәт вазифасы нигезендә муниципаль хезмәткәрнең вазифаи окладыннан (алга таба – вазифаи оклад), шулай ук Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы белән билгеләнгән айлык һәм башка өстәмә түләүләрдән торган (алга таба – өстәмә түләүләр) акчалата түләү рәвешендә башкарыла.

2. Өстәмә түләүләргә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле елларны хезмәт иткән өчен вазифаи окладка ай саен өстәмә түләү;

2) муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазифаи окладка ай саен өстәмә түләү;

3) түләү тәртибе муниципаль органның бурычларын һәм функцияләрен, вазифаи инструкцияләрнең үтәлешен тәэмин итүне исәпкә алып, яллаучының вәкиле (эш бирүче) билгели торган аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр;

4)айлык акчалата бүләкләү;

5) класслы чин өчен ай саен өстәмә түләү;

6) ел саен бирелә торган отпуск биргәндә бер тапкыр түләү;

7) матди ярдәм.

3. Россия Федерациясенең Бюджет кодексы белән билгеләнгән таләпләрне үтәп, муниципаль хокукый актлар белән түбәндәге өстәмә түләүләр күздә тотылырга мөмкин:

1) нормадан арткан эш көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләүләре;

2) хокукый актларга һәм хокукый актларның проектларына хокукый экспертиза уздыру, хокукый актлар проектларын редакцияләү һәм әзерләү һәм аларны югары юридик белемле (юридик эш өчен өстәмә түләү) юрист яисә башкаручы сыйфатында визалаштыру төп хезмәт вазифаларына кергән муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә түләү;

3) фәннәр кандидатының профильле галим дәрәҗәсе, фәннәр докторының галим дәрәҗәсе өчен муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладына айлык өстәмә түләү;

4) Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладына ай саен өстәмә түләү.

4. Закон нигезендә дәүләт сере саналган мәгълүматлар белән эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрнең вазифаи окладына ай саен өстәмә түләү билгеләнә.

5. Җирле үзидарә органнары мөстәкыйль рәвештә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү күләмен һәм шартларын билгелиләр. Вазифаи оклад күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме һәм башкару тәртибе Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы тарафыннан чыгарылган муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

27. Муниципаль хезмәткәргә бирелә торган гарантияләр

1. Муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр гарантияләнә:

1) вазифаи инструкция нигезендә вазифаи бурычларны башкаруны тәэмин итүче эш шартлары;

2) үз вакытында һәм тулы күләмдә акчалата тәэмин ителеш хокукы;

3) эш (хезмәт) вакытының нормаль озынлыгын билгеләүне, ял көннәрен һәм эшләми торган бәйрәм көннәрен, шулай ук ел саен бирелә торган түләүле отпускны тәэмин итүче ял;

4) муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын, шул исәптән, муниципаль хезмәткәр лаеклы ялга чыккач медицина хезмәте белән тәэмин итү;

5) тиешле елларны хезмәт иткән өчен һәм инвалидлыкка бәйле рәвештә, пенсия белән тәэмин итү, шулай ук вазифаи бурычларны башкару белән бәйле рәвештә, ул вафат булган очракта, муниципаль хезмәткәрнең гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү;

6) вазифаи бурычларны башкару белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә һәм милкенә зыян килгән очракка мәҗбүри дәүләт иминияте;

11) муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узган чорда яисә эшләүдән туктаган чорда вазифаи бурычларын үтәгәндә авырган яисә хезмәткә сәләтен югалткан очракта, мәҗбүри социаль иминият;

8) муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә, очракларда аларның вазифаи бурычларын үтәве белән бәйле көчләүдән, янаудан һәм башка хокукка каршы гамәлләрдән саклау.

3.Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе ликвидацияләнүгә, яисә җирле үзидарә органы хезмәткәрләренең штаты, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты кыскартылу белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүен өзгәндә, муниципаль хезмәткәргә оешма ликвидацияләнү яисә оешма хезмәткәрләренең штаты кыскартылуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән очракта хезмәткәрләргә хезмәт законнары белән билгеләнгән гарантияләр бирелә.

3. Муниципаль берәмлек Уставы нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә гарантияләр бирелергә мөмкин.

### 28. Муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү

1. Җирле үзидарә органнарында, Минзәлә муниципаль районында муниципаль органнарда (алга таба – җирле үзидарә органнары) муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштырган муниципаль хезмәткәрләр Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы, гамәлдәге Нигезләмә нигезендә, гамәлдәге пунктның 1.1, 1.2, һәм 2.1 өлешләрендә билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, түбәндәге шартларда тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсиягә хокуклы:

   1)озынлыгы тиешле елларны хезмәт иткән өчен кирәкле елда 25.06.2013 елдагы №50-ЗРТ Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында Кодексына 5 кушымта нигезендә билгеләнә торган муниципаль

хезмәт стажы булу.

2) гамәлдәге нигезләмәнең 29 пункты, 2 өлеше, “е” подпункты, 1 һәм 2 пунктларның 1 өлешендә күрсәтелгән, шулай ук гамәлдәге пунктның 2.1 өлеше нигезендә башка вазыйфаларда 10 елдан ким булмаган эш (хезмәт) стажы булу;

3) Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең соңгы башкарган вазыйфасыннан азат ителү һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтеннән түбәндәге нигезләмәләрдә каралганча азат ителү:

а) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законның 19 маддә 1 өлеше 1 һәм 3 пунктлары нигезендә (муниципаль хезмәткәрне эшкә яраксыз яисә суд карары белән эшкә яраклылыгы чикле итеп тану);

б) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 83 маддә 7 өлеше һәм 2,5 пунктлары, 81 маддә беренче өлеше 1-3 пунктлары, 77 маддә беренче өлеш 7-9, 1-3, 5 пунктлары белән (дәүләт хезмәтенә күчерелгән яисә сайланган эшкә (вазифага) күчкән очракта);

1.1. Муниципаль хезмәткәрләр “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законның 19 маддә 1 өлеш 1 пунктында, 1,2 пунктында (муниципаль хезмәткәр алмаштырган вазыйфа оештырылган вәкаләтләрне башкаруны турыдан-туры тәэмин итү өчен, муниципаль вазыйфа алмаштырган затның вәкаләтләренең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә хезмәт килешүе срогы чыккан очраклардан тыш), Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 маддә беренче өлеше 3 пункты, 77 маддә беренче өлеше 3 һәм 7 өлеше нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән азат ителгәндә, “Иминият пенсияләре турында”гы Федераль законның 8 маддә 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче яшькә җитсәләр, яисә гамәлдәге пунктның 2 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, инвалидлык буенча иминият пенсиясе яисә вакытыннан алда картлык буенча пенсия билгеләнгән булса, тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсиягә чыгарга хокуклы.

1.2. Муниципаль хезмәткәрләр Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән азат ителгәндә “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законның 19 маддә 1 өлеше 3 пунктында (законлы көченә кергән суд карары белән муниципаль хезмәткәр эшкә яраксыз яисә өлешчә эшкә яраксыз дип танылган очракта), 2 пункты (муниципаль хезмәткәр алмаштырган вазыйфа оештырылган вәкаләтләрне башкаруны турыдан-туры тәэмин итү өчен, муниципаль вазыйфа алмаштырган затның вәкаләтләренең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә хезмәт килешүе срогы чыккан очраклардан тыш), 5 пункты

(дәүләт хезмәтенә күчерелгән яисә сайланган эшкә (вазыйфага) күчкән очракта), Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 маддә беренче өлеше 8 һәм 9 пунктлары, 81 мадданең беренче өлеше 1 һәм 2 өлеше, 83 маддә, беренче өлеше 2, 5 һәм 7 пунктларында каралганча, эштән азат ителгән вакытка картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә хокукын алуга бәйсез рәвештә, тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсиягә чыгарга хокуклы.

2. Муниципаль хезмәткәрләр Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән азат ителгәндә "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы Федераль законның 19 маддә 1 өлеш 1 пункты, 1,2 пункты (муниципаль хезмәткәр алмаштырган вазыйфа оештырылган вәкаләтләрне башкаруны турыдан-туры тәэмин итү өчен, муниципаль вазыйфа алмаштырган затның вәкаләтләренең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә хезмәт килешүе срогы чыккан очраклардан тыш), Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 маддә беренче өлеше 3 һәм 7 пунктлары, 81 мадданең 77 маддә беренче өлеш 3 пункты нигезендә, "Иминият пенсияләре турында"гы Федераль законның 8 маддә 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче яшькә җиткәнче, яисә инвалидык буенча иминият пенсиясенә яисә вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясе билгеләү яше җиткәнче, гамәлдәге Нигезләмәнең 29 пункты 3 өлеше "е" подпунктында, 1 өлешнең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән вазифаларда, шулай ук гамәлдәге пунктның 2.1 өлеше нигезендә вазифаларда кимендә 15 ел эш стажы (хезмәт) булган шартта тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсиягә чыгарга хокуклы.

2.1. Гамәлдәге пунктның 2 өлеше, 1 өлеше 2 пунктында күрсәтелгән эш (хезмәт) стажына гамәлдәге Нигезләмәнең 29 пункты 2 өлеше 3 пункты "а" - "д", "ж" и "з" подпунктларында, 1,2 пунктларда, 1 өлеше, 4 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән вазифаларда гомуми озынлыгы 5 елдан артык булмаган, әгәр әлеге чорлар турыдан-туры гамәлдәге Нигезләмәнең 29 пункты 2 өлеше 3 пункты "е" подпункты, 1 өлешнең 1 һәм 2 пунктлары нигезендә күрсәтелгән вазифаларда эше (хезмәт) артыннан турыдан-туры һәм (яки) алдыннан турыдан-туры барган булса, Татарстан Республикасында эш (хезмәт) стажы чоры исәпләнә. Бер үк вакытта гамәлдәге Нигезләмәнең 29 пункты 2 өлеше 3 пункты "е" подпунктында, 1 өлеше 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән вазифаларда эштән (хезмәттән) соң һәм аңа кадәр эзлекле башкарылган, гамәлдәге Нигезләмәнең 29 пункты 2 өлеше 3 пункты "а" – "д", "ж" һәм "з" подпунктларында, 1,2 пунктларда, 1 өлеше, 4 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән вазифаларда эшнең (хезмәт) барлык чорлары исәпкә алына.

3. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия "Иминият пенсияләре турында"гы Федераль законның 8 маддә 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче, яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе яисә вакытыннан алда иминият пенсиясен билгеләү

хокукы бирүче яшькә җиткәч билгеләнә. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия гомерлек билгеләнә һәм ай саен түләнә.

4. Муниципаль хезмәткәрләргә озынлыгы 25.06.2013 елдагы Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы №50-ЗРТның 5 кушымтасы нигезендә билгеләнә торган тиешле елда тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия тиешле муниципаль хезмәт стажы булганда, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата түләүләренең 20 проценты күләмендә билгеләнә. Күрсәтелгән стаждан артыграк муниципаль хезмәттә һәр тулы ел стаж өчен тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия айлык акчалата түләүнең 3 проценты кадәр арта бара. Шул ук вакытта тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата түләүләренең 50 процентыннан югары була алмый.

4.1. Гамәлдәге пунктның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия күләме “Иминият пенсияләре турында”гы Федераль законның 16 маддә 1 өлеше нигезендә билгеләнгән картлык буенча иминият пенсиясенә билгеләп куелган түләүдән артмаган очракта, тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия картлык буенча иминият пенсиясенә билгеләп куелган түләүгә тигез күләмдә түләнә.

5. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия күләмен билгеләү Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларында һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларындагы тәңгәллек белән Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексында билгеләнгәнчә башкарыла. Муниципаль хезмәткәрнең тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия күләме Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтендә тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсиянең максималь күләменнән артык була алмый.

.

6. Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсиянең максималь күләмен исәпләгәндә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи окладның максималь күләме кулланыла (әгәр вазыйфаи окладның максималь һәм минималь күрсәткече булса), ә стаж озынлыгы һәм айлык түләүләр Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексында билгеләнгәнчә, тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук күрсәткечтә исәпкә алына.

7. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия күләме муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасы буенча муниципаль хезмәтне төгәлләгән көннән яисә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче яшькә җиткән көннән, муниципаль хезмәтнең вазыйфасы буенча айлык

акчалата түләүдән чыгып (әлеге вазыйфада эшләү вакыты тулы 12 айдан да ким булмаган шартта), тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү өчен мөрәҗәгать итүче затның сайлавы буенча исәпләнә.

Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән вакытка муниципаль хезмәтнең күрсәтелгән вазыйфалары ликвидацияләнгән очракта, акчалата түләү күләме шуңа тәңгәл яисә муниципаль хезмәтнең вазыйфасына тигез итеп билгеләнә. Муниципаль хезмәтләрнең тәңгәллеге Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

8. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия исәпләнә һәм билгеләнә торган айлык акчалата түләү составына вазыйфаи оклад һәм класслы чин өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү кертелә.

9. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия гамәлдәге пунктның 1 һәм 2 өлешләре нигезендә тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия алуга хокукы булган, шул исәптән электрон документ формасында бирелгән гражданинның гаризасы буенча башкарыла.

10. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү турындагы гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) паспорт яки шәхесне раслаучы башка документ күчермәсе, яше, кайсы гражданлыкка каравы;

2) хезмәт кенәгәсе күчермәсе, шулай ук кирәк булганда, гамәлдәге Нигезләмәнең 30 пунктында күрсәтелгән һәм муниципаль хезмәт стажын раслаучы башка документлар күчермәсе;

3) Муниципаль хезмәткәрнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи окладны һәм айлык түләүләрнең күләмен эченә алган, шулай ук муниципаль хезмәтнең үзенчәлекле шартлары өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү билгеләнгән датаны эченә алырга тиеш тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән затның айлык акчалата түләве күләме турында белешмә.

11. Гамәлдәге пунктның 10 өлеше 1-3 пунктларында күрсәтелгән документларның күчермәләре белән бергә, документлар кабул иткәндә күчермәләр белән чагыштырыла һәм гариза бирүчегә кайтарып бирелә торган документларның төп нөсхәсе тапшырыла.

7. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия түләү тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләнгән затның яшәү урыны буенча башкарыла. Пенсионер тору урынын алыштырган вакытта, тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия түләү, аны китереп бирүне оештыруны кертеп, аның

яңа яшәү урыны буенча яисә теркәү учеты органнары билгеләгән тәртиптә бирелгән теркәү турындагы документлар һәм пенсия эше нигезендә килгән урын буенча башкарыла.

8. Татарстан Республикасы территориясе чикләреннән даими яшәү урынына чыгып киткән (чыккан) затларга тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия түләү Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия түләү өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

9. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия гариза тапшырган көннән исәпләнә һәм түләнә, шул исәптән электрон документ формасында, әмма муниципаль хезмәттән яисә муниципаль вазифадан, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан яисә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасыннан, яисә дәүләт вазыйфасыннан яисә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасыннан, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасыннан яисә федераль дәүләт хезмәте вазыйфасыннан азат ителгән көннән иртәрәк түгел, һәм гамәлдәге пунктның 3 өлешендә каралган шартларны үтәп башкарыла.

10. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләнгән затның гамәлдәге пунктның 14 өлешендә күрсәтелгән вазыйфасын алмаштырган очракта, күрсәтелгән вазыйфаларның берсен алмаштырган көннән башлап, тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия түләү туктатылып торыла. Әлеге затларның күрсәтелгән вазыйфалардан азат ителүеннән соң, аларга тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия тәүләү элекке шартларда кабаттан торгызыла яисә шул исәптән электрон документ формасында бирелгән гариза буенча пенсия Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең соңгы вазыйфасы буенча яңадан билгеләнә.

11. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсияне индексацияләү (өстәмә арттыру) муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфалары буенча вазыйфаи окладларның арту индексына гамәлдәге пунктның 4 өлеше кагыйдәләре буенча исәпләнгән тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия күләмен арттыру юлы белән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын үзәкләштерелгән тәртиптә күтәргәндә башкарыла.

Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия күләмен кабаттан исәпләү (төзәтмәләр кертү) гамәлдәге пунктның 4 һәм 4 өлешләре нигезендә, шул исәптән электрон рәвештә тапшырылган пенсионерның гаризасы буенча муниципаль хезмәт стажы озынлыгы билгеләнгән тәртиптә үзгәртелгән очракта башкарыла. Бу очракта пенсия күләмен кабаттан исәпләү пенсионерның гаризасы кабул ителгән айдан соң килүче айның беренче числосыннан башкарыла.

Әгәр федераль законнар нигезендә башкача билгеләнмәгән икән, бер үк вакытта Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы нигезендә тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсиягә һәм дәүләт гражданлык хезмәтендә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия федераль законнар, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары законнары, җирле үзидарә орагннары актлары нигезендә федераль бюджет акчаларыннан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, Россия Федерациясенең башка субъектлары бюджетыннан, җирле бюджеттан билгеләнә һәм финанслана торган башка нигезләмәләр буенча тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия, ай саен гомерлек түләү, Татарстан Республикасында дәүләт вазыйфаларын яисә Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны башкаручы затларның пенсияләренә ай саен өстәмә түләү, өстәмә айлык (гомерлек) матди тәэмин ителеш, инвалидлык буенча пенсия (инвалидлык буенча иминият пенсиясеннән тыш), картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә башка айлык өстәмә түләү Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия яисә аның сайлавы буенча башка түләү түләнә.

18. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсияне билгеләү, күләмен кабаттан исәпләү һәм түләү, аларны китереп бирүне оештыру Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсияләрне билгеләү һәм түләүне башкаручы орган тарафыннан үтәлә.

19. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсияне түләү, аны китереп бирү, пенсиядән тотып калу, әгәр дә Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексында башкача каралмаган булса, иминият пенсиясеннән тотып калу һәм китереп бирү, түләү өчен каралган тәртиптә башкарыла.

15. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсияне билгеләү өчен мөрәҗәгать итү, пенсияне билгеләү һәм күләмен кабаттан исәпләү, пенсияне түләү, пенсия документациясен алып бару Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсияләрне билгеләү һәм түләү өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

16. Муниципаль хезмәткәрнең вазифаи бурычларны башкару белән бәйле үлеме, шул исәптән, аның муниципаль хезмәттән азат ителгәч үлүе очрагында, вафат булучының гаилә әгъзалары федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә туйдыручысын югалту очрагы буенча пенсия алуга хокук алалар.

22.Гамәлдәге нигезләмә нигезендә тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү һәм түләү турында мәгълүмат социаль тәэмин ителешнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүматне социаль тәэмин ителешнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (алу) 1999 елның 17 июлендәге "Дәүләт социаль ярдәме турында"гы №178-ФЗ Федераль законы нигезендә башкарыла.

29. Муниципаль хезмәт стажы

1. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажына (гомуми озынлыгы) даими (штат) нигездә эшләгән (алмаштырган) чорлар кертелә:

1) муниципаль хезмәт вазыйфаларында (муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфаларында). Бер үк вакытта 2006 елның 1 гыйнварыннан муниципаль хезмәт стажына Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары Реестрында каралган вазыйфаларда Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында, ә ул расланганга кадәр - Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфалары Реестрында каралган эш чорлары кертелә;

2) муниципаль вазифаларда;

2) гамәлдәге пунктның 2 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларында һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларында, Татарстан Республикасының (Татар АССР) дәүләт органнарында башка дәүләт вазыйфаларында;

3) Россия Федерациясенең дәүләт вазыйфаларында, федераль дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларында, СССР дәүләт органнары вазыйфаларында, союз һәм автоном республикаларда, крайларда, өлкәләрдә, автоном өлкәләрдә һәм автоном округларда, район, шәһәр, шәһәрләрдәге район, халык депутатларының поселок һәм авыл советларында һәм аларның башкарма комитетларында, шул исәптән, сайланган, федераль законнар нигезендә, тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия алырга хокук бирүче федераль дәүләт гражданлык хезмәте стажын исәпләгәндә күрсәтелгән вазыйфаларда эш (хезмәт) вакыты булган шартта даими нигездә;

4) җәзаларны үтәтү системасы органнарында һәм учреждениеләрендә, Дәүләт янгынга каршы хезмәттә, эчке эшләр органнарындагы хезмәттә, хәрби хезмәтне узган затларга тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү өчен тиешле елларны хезмәт иткән елларга Россия Федерациясе законнары нигезендә исәпләнә торган хезмәт (хәрби хезмәт) узу, вазыйфа (хәрби вазыйфа);

5) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфалар исемлеге нигезендә билгеләнгән салым полициясенең федераль органнары һәм наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту буенча органнары хезмәткәрләре вазыйфаларында;

7) федераль закон нигезендә билгеләнә торган Россия Федерациясенең таможня органнары хезмәткәрләре вазифаларында;

12) федераль закон нигезендә билгеләнә торган прокурор хезмәткәрләре вазифаларында;

13) федераль закон нигезендә җирле үзидарә органында яисә дәүләт органында булдырылган беренчел профсоюз оешмасы органына сайлану (вәкил итеп җибәрелү), азат ителгән профсоюз хезмәткәрләре башкарган вазыйфаларны кертеп, профсоюз органнарына сайлау (вәкил итеп җибәрү) нәтиҗәсендә дәүләт органнарында яисә җирле үзидарә органнарында вазыйфалардан азат ителгән хезмәткәрләр башкарган профсоюз органнарындагы вазыйфаларда;

10) җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр, сайланган вазифалардагы вазифаларда:

а) 1991 елның 6 ноябрен кертеп, КПССның үзәк, республика, өлкә һәм район (шәһәр) органнарында, шулай ук предприятиеләрдәге парткомнарда, райком хокукы булган оешмаларда ;

б) 1990 елның 26 октябрен кертеп, профсоюз органнарының республика һәм җирле аппаратларында;

14) 2001 елның 1 гыйнварыннан 2013 елның 31 мартын кертеп, Татарстан Республикасының шәһәр һәм районнарындагы Россия Федерациясенең Пенсия фонды идарәләрнедә, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча Бүлекчә белгечләре, җитәкчеләре вазыйфаларында;

12) федераль законнар нигезендә башка вазифаларда.

3. Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасының (Татар АССР) дәүләт органнарында башка дәүләт вазыйфаларын башкарган чорлар түбәндәге тәртиптә тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажына кертелә:

1) Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларының Гомуми исемлеге һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык вазыйфалары

Реестрында каралган дәүләт хезмәте вазыйфаларында һәм Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларында эш (хезмәт) чорлары, шулай ук әлеге вазыйфалар дәүләт хезмәте вазыйфалары тиешле исемлегенә алга таба кертелгән очракларда, күрсәтелгән Реестр расланганнан соң, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары Реестрына кертелмәгән дәүләт органнары вазыйфаларында эш (хезмәт) чорлары;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт вазыйфалары Реестрында каралган вазыйфаларда Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары Реестры һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларының Гомуми исемлеге расланганга кадәр 1995 елның 26 маеннан эш (хезмәт) чорлары, шулай ук әлеге вазыйфаларны дәүләт вазыйфаларының яисә дәүләт хезмәте вазыйфаларының тиешле исемлегенә алга таба серткән очракта, татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт вазыйфалары Реестрында каралмаган вазыйфаларда;

3) 1995 елның 26 маена кадәр җитәкчеләрнең, белгечләрнең, хезмәткәрләрнең, сайланган вазифаларның үз вазифаларын алмаштыру чорлары:

а) Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында һәм аның Аппаратында, Татарстан Республикасының Дәүләт контроль (парламент) комитетында һәм аның аппаратында;

в) Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетында һәм аның Аппаратында;

г) министрлыкларда, дәүләт комитетларында, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең башка органнарында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы дәүләт органнарында (идарә органнарында);

д) Татарстан Республикасы вәкиллекләрендә;

е) дәүләт хакимиятенең җирле органнарында һәм идарәләрендә (район, шәһәр, халык депутатларының шәһәр, район Советында, район хакимиятләрендә, республика әһәмиятендәге шәһәрләр, шәһәрләрдәге районнар) һәм аларның аппаратларында;

ж) Татарстан Республикасының конституцион күзәтчелеге Комитетында;

з) Татарстан Республикасында халык депутталарын сайлау буенча Үзәк сайлау комиссиясендә;

4) җитәкче, белгеч, хезмәткәр, сайланган вазифаларда вазифалар башкарган

чорларга түбәндәге чорлар керә:

а) Татарстан Республикасының Югары Советында (Татар АССРның Югары Советында) һәм Татар АССРның Югары Советы Президиумында, халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрләрдәге район, поселок, авыл Советларында һәм аларның аппаратларында;

б) Татар АССР Министрлар Советында (Татар АССР Министрлар Советында) һәм аның аппаратында, район башкарма комитетларында, шәһәр, шәһәрләрдәге район, халык депутатларының авыл һәм бистә Советларында;

в) Татар АССР Министрлар Советының дәүләт идарәсе органнарында, Татар АССРның Министрлар Советы каршындагы дәүләт идарәсе органнарында, Татар АССРның министрлыкларында һәм ведомстволарында.

3. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажына Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы законы нигезендә муниципаль хезмәткәрнең өстәмә һөнәри белем алган вакыты, шулай ук федераль законнар нигезендә муниципаль хезмәткәрдә муниципаль хезмәт вазыйфасы сакланган башка чорлар кертелә.

4. “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы , аларга федераль законнар белән каралган башка гарантияләр билгеләү һәм муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган тиешле елларны хезмәт иткән өчен ел саен өстәмә түләүле отпуск озынлыгын билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажына “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законның 25 маддә 1 өлешендә күрсәтелгән, шулай ук 2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында”гы №79-ФЗ Федераль законының 54 маддә 2 өлеше нигезендә дәүләт гражданлык хезмәте стажына кертелгән (исәпләнгән) вазифаларны башкарган чорлар кертелә.

30. Муниципаль хезмәт стажын исәпләү һәм билгеләү тәртибе

1. Муниципаль хезмәт стажын исәпләү хәрби хезмәтнең бер көнен ике көн исәбеннән санала торган гражданның хәрби хезмәттә чакырылыш буенча булу вакытыннан тыш, календарь тәртиптә башкарыла. Муниципаль хезмәт стажын санаганда хезмәт (эш) чорлары бергә кушыла.

2. Билгеләнгән үрнәктәге хезмәт кенәгәсе муниципаль хезмәт стажын раслаучы төп документ булып тора. Муниципаль хезмәт стажын санаганда исәпкә алына торган хезмәт кенәгәсендәге язмалар хезмәт кенәгәсенә кертелгән көнгә гамәлдә булган хезмәт законнары нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш. Муниципаль хезмәт стажына кертелә торган хезмәт (эш) чорларын раслау өчен нигез булып торган, дөрес булмаган яисә төгәл булмаган мәгълүматлар хезмәт

кенәгәсендә булган очракта, федераль законнарда каралган тәртиптә хезмәт кенәгәсенә үзгәрешләр кертелә.

3.Хезмәт кенәгәсендә муниципаль хезмәт стажын раслаучы язмалар булмаган очракта, әлеге стаж бу стажга кертелә торган вазыйфаларда хезмәт (эш) чорларын раслаучы вазыйфага билгеләү һәм азат итү турындагы документларның күчермәләрен беркетеп тапшырылган белешмәләр нигезендә раслана.

5. Хәрби хезмәт узган чорлар, аңа тиңдәш башка хезмәт, шулай ук хезмәткәрләрнең салым полициясе, таможня органнары федераль органнарында хезмәт иткән чорлары хәрби билет, хәрби комиссариатларның, хәрби подразделениеләрнең, архив учреждениеләренең белешмәләре, хезмәт кенәгәсендәге, хезмәт дәфтәрендәге язмалар белән расланырга мөмкин.

5. Гамәлдәге Нигезләмәнең 29 пунктында каралган вазыйфаларда хезмәт (эш) итү чорларын раслау өчен кирәкле шартларда, аларның вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү турында хокукый актларның күчермәләре яисә алардан чыгармалар тапшырылырга мөмкин.

6. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү билгеләү, тиешле елларны хезмәт иткән өчен ел саен өстәмә түләүле отпуск озынлыгын билгеләү, хезмәттә югары казанышлары өчен бүләкләү күләме муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия карары нигезендә, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын башкарган җирле үзидарә органының акты белән билгеләнә. Күрсәтелгән комиссия җирле үзидарә органының хокукый акты белән булдырыла.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия турында нигезләмә җирле үзидарә органы белән раслана.

7. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажы гамәлдәге Нигезләмә нигезендә, муниципаль хезмәт стажын раслаучы билгеләнгән тәртиптә тапшырылган документлар нигезендә тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү буенча вәкаләтле орган тарафыннан тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсия билгеләү өчен муниципаль хезмәткәрнең гаризасы буенча билгеләнә.

## VII. Муниципаль хезмәткәрне бүләкләү, муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы

### 31. Муниципаль хезмәткәрне бүләкләү

1. Муниципаль хезмәткәрнең үз вазифаларын намус белән һәм нәтиҗәле башкаруы, бик яхшы хезмәте, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгәне өчен түбәндәге төрдә бүләкләүләр кулланылырга мөмкин:

1) рәхмәт белдерү;

2) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү;

3) кыйммәтле бүләк тапшыру;

4) мактау кәгазе яисә җирле үзидарә органнары билгеләгән башка төр бүләкләр;

5) законнар нигезендә дәүләт бүләкләре тапшыру;

6) “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский ис. авыл җирлеге“ муниципаль берәмлегеУставы һәм Татарстан Республикасы законнары һәм федераль законнар нигезендә башка муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнгән башка төр бүләкләүләр.

2. Гамәлдәге пунктның 1 өлешендә каралганча, бүләкләүләрне куллану шартлары һәм тәртибе муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

32. Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы

1.Дисциплинар хата кылган өчен – муниципаль хезмәткәрнең гаебе буенча аңа йөкләнгән вазифаи бурычларның тиешенчә үтәлмәве яисә үтәлмәве өчен яллаучы вәкиле (эш бирүче) түбәндәге дисциплинар җәзалар кулланырга хокуклы:

1) кисәтү;

2) шелтә;

3)тиешле нигезләр буенча муниципаль хезмәттән азат ителү.

2. Дисциплинар хата ясаган муниципаль хезмәткәр вакытлыча (әмма бер айдан озаграк түгел), аның дисцилинар җаваплылыгы турында мәсьәлә хәл ителгәнче, акчалата түләүне саклап, вазифаи бурычларын үтәүдән читләштерелергә мөмкин. Муниципаль хезмәткәрне вазифаи бурычларын үтәүдән читләштерү бу очракта муниципаль хокукый акт белән башкарыла.

3. Дисциплинар җәзаны куллану һәм кире алу тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә.

33. Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән вазифаларны үтәмәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яисә булдырмау турында таләпләрне, тыюларны һәм чикләүләрне үтәмәгән өчен җәзалар

Муниципаль хезмәткәрнең коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән вазифаларны үтәмәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яисә булдырмау

турында таләпләрне, тыюларны һәм чикләүләрне үтәмәгән өчен җәзалар “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законы, “Коррупциягә каршы тору турында”гы Федераль законы, башка федераль законнары нигезендәгамәлдәге Нигезләмәнең 32 пунктында каралган җәзалар бирелә.

2. Гамәлдәге Нигезләмәнең 17 һәм 18 пунктларында каралган хокук бозулар кылган очракларда, ышанычны югалтуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттән азат ителергә тиеш.

3. Гамәлдәге Нигезләмәнең 17, 18 һәм 32 пунктларында каралган җәзалар яллаучының вәкиле (эш бирүче) тарафыннан түбәндәге нигездә кулланыла:

1) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте подразделениесе (алга таба – хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте подразделениесе) тарафыннан уздырылган тикшерү нәтиҗәләре турында доклады;

2) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәттә үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм, әгәр дә тикшерү нәтиҗәләре буенча доклад комиссиягә җибәрелгән булган очракта, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия рекомендацияләре;

3) коррупцион хокук бозу кылыну фактын таныган шартта һәм муниципаль хезмәткәр ризалыгы белән аның язмача аңлатмасы, аның чынлыкта кылынуы бәян ителгән коррупцион хокук бозу кылыну турында хокук бозулар профилактикасы буенча кадрлар хезмәте подразделениесе доклады (ышаныч югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә шелтә куллanudан тыш);

4) муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары;

5) башка материаллар.

4. Язма рәвештә тапшырылган җитәрлек мәгълүмат хокук бозулар профилактикасы буенча кадрлар хезмәте подразделениесенең тикшерү уздыруына нигез булып тора:

1) хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазифаи затлары тарафыннан;

2) сәяси партияләрнең, шулай ук сәяси партия булмаган төбәк иҗтимагый берләшмәләр законнары нигезендә теркәлгән төбәк һәм җирле бүлекчәләре тарафыннан;

3) Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегендә булдырылган иҗтимагый совет тарафыннан;

4) массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан.

5. Аноним хәбәрләр хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте подразделениесе тарафыннан тикшерү уздыру өчен нигез була алмый.

6. Тикшерү уздырганчы хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте подразделениесе муниципаль хезмәткәрдән язмача формада аңлатма таләп итәргә тиеш. Әгәр ике эш көне эчендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән аңлатма бирелмәгән очракта, тиешле акт төзелә. Муниципаль хезмәткәрнең аңлатма тапшырмавы тикшерү уздыру өчен нигез була алмый.

7. Муниципаль хезмәткәр гамәлдәге Нигезләмәнең 17 пунктында 5 яисә 7 нче өлешендә каралган хокук бозуларны кылган очракта, тикшерү нәтиҗәләре турында доклад, муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасы һәм башка материаллар хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәтенең подразделениесе тарафыннан муниципаль хезмәткәргә дисциплинар җәза куллану буенча яллаучының вәкиленә (эш бирүчегә) рекомендацияләр әзерләүче мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәттә үз-үзләрен тотуга таләпләрне үтәү буенча комиссиягә тапшырыла.

Муниципаль хезмәткәр башка хокук бозу кылган очракта, тикшерү нәтиҗәләре турында доклад, муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасы һәм башка материаллар хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте подразделениесе тарафыннан яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) тапшырыла.

8. Гамәлдәге Нигезләмәнең 17, 18 һәм 32 пунктларында каралган җәзалар кулланганда, муниципаль хезмәткәр кылган коррупцион хокук бозуның характеры, аның авырлыгы, аның нинди шартларда кылынуы, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәве һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында яисә булдырмау турында таләпләрнең, тыюларның һәм башка чикләүләрнең муниципаль хезмәткәр тарафыннан үтәлүе, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең моңа кадәр үз вазифаи бурычларын башкару нәтиҗәләре.

9. Гамәлдәге Нигезләмәнең 17, 18 һәм 32 пунктларында каралган шелтәләр муниципаль хезмәткәрнең коррупцион хокук бозу кылынуы ачыкланган көннән соң бер айдан да соңармыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә яраксыз чорын, отпускта булу, башка сәбәп белән хезмәттә булмау вакытын исәпкә алмыйча, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу һәм муниципаль хезмәткәрнең хезмәттә үз-үзен тоту таләпләрен үтәү буенча комиссия тарафыннан күрсәтелгән тикшерүнең материалларын карау һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте подразделениесе тарафыннан тикшерү уздыру вакыты кулланыла. Шул ук вакытта җәза коррупцион хокук бозу кылынган көннән башлап, алты айдан да соңармыйча кулланылырга мөмкин.

10. Муниципаль хезмәткәр коррупцион хокук бозу кылган очракта аңа карата җәза куллану турында актта “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законының 27.1 маддәсенең 1 һәм 2 өлеше күрсәтелә.

11. Муниципаль хезмәткәргә җәза куллану турында акт күчермәсе ул нигезләмәләрен бозган хокук бозуларны һәм норматив хокукый актларны, нигезләмәләрне күрсәтеп, яисә мотивны күрсәтеп муниципаль хезмәткәргә карата андый җәза куллануны кире кагып, тиешле акт язылган көннән өч эш көне эчендә муниципаль хезмәткәргә расписка белән тапшырыла. Әгәр муниципаль хезмәткәр күрсәтелгән расписканы бирергә теләмәсә, тиешле акт төзелә.

12. Җәзага муниципаль хезмәткәр тарафыннан федераль закон нигезендә шикаять бирелергә мөмкин.

13. Әгәр җәза кулланылган муниципаль хезмәткәр бер ел дәвамында гамәлдәге Нигезләмәнең 32 пункты 1 һәм 2 өлешендә каралган дисциплинар җәза алмаса, ул җәза алмаган булып санала.

14. Яллаучы вәкиле (эш бирүче) муниципаль хезмәткәрдән гамәлдәге Нигезләмәнең 32 пункты 1 һәм 2 бүлекләрендә каралган дисциплинар җәзаны үз инициативасы белән, муниципаль хезмәткәрнең гаризасы буенча яисә аның турыдан-туры җитәкчесенең язмача гаризасы буенча, дисциплинар җәза кулланылганнан соң бер ел тулганчы алырга хокуклы.

15. Муниципаль хезмәткәргә ышаныч бетү сәбәпле эштән азат итү рәвешендә җәза куллану муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узган җирле үзидарә органына карата куллану турында мәгълүматлар 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында"гы №273-ФЗ Федераль законның 15 маддәсендә каралганча, ышаныч югалтуга бәйле рәвештә азат ителгән затлар реестрына кертеләләр.

## VIII. Муниципаль берәмлектә кадрлар эше

34. Муниципаль берәмлектә кадрлар эше үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) муниципаль хезмәт вазифаларын башкару өчен кадрлар составын формалаштыру;

2) муниципаль хезмәт турында законнар нигезләмәләрен тормышка ашыру турында тәкъдимнәр әзерләү һәм күрсәтелгән тәкъдимнәрне яллаучының вәкиленә (эш бирүчегә) тапшыру;

4) муниципаль хезмәткә керү, аны узу, хезмәт килешүен (контракт) төзү, муниципаль хезмәт вазифасына билгеләү, муниципаль хезмәт вазифасыннан азат ителү, муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттән азат ителүе һәм аның пенсиягә чыгуы, һәм кирәкле документлар рәсмиләштерү белән бәйле муниципаль хокукый актларның проектларын әзерләүне оештыру;

4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару;

5) “Россия Федерацясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законның 30 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси эшләрен алып бару;

6) муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләрнең реестрын алып бару;

7) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт таныклыкларын рәсмиләштерү һәм бирү;

8)муниципаль хезмәтнең вакантлы вазифаларын алмаштыруга конкурс уздыру һәм муниципаль хезмәткәрләрне кадрлар резервына кертү;

9) муниципаль хезмәткәрләрнең аттестациясен уздыру;

10) кадрлар резервы белән эшне оештыру һәм аннан нәтиҗәле файдалану;

11) муниципаль хезмәткә кергәндә гражданин тапшыра торган персональ мәгълүматларның һәм башка мәгълүматларның дөреслеген тикшерүне уздыру, шулай ук дәүләт сере булып саналган билгеләнгән формадагы мәгълүматларга керүне оештыру;

12) муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы вазифалар турындагы мәгълүматларны тикшерүне оештыру, шулай ук “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль законның 13 маддәсе һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләрнең үтәлешен оештыру;

13) муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең хокукый һәм башка мәсьәләләре буенча консультация бирү;

14) Гамәлдәге Кодекс һәм хезмәт законнары белән билгеләнгән кадрлар эшенең башка мәсьәләләрен чишү.

34.1. Муниципаль хезмәт өчен кадрларны килешү нигезендә әзерләү

1. Муниципаль хезмәтнең югары квалификацияле кадрлар составын формалаштыру максатларында, Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законнарның нигезләмәсен исәпкә алып, Россия Федерациясендә белем бирү турында законнар нигезендә килешү нигезендә муниципаль хезмәт өчен гражданнарны әзерләүне оештыруны башкара алалар.

2. Алга таба муниципаль хезмәт узу бурычы белән максатчан белем бирү турындагы килешү (максатчан белем бирү килешүе) җирле үзидарә органы һәм гражданин арасында төзелә һәм уку тәгәлләнгәннән соң билгеләнгән срок эчендә күрсәтелгән җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт узу буенча

гражданинның бурычын күздә тота.

3. Максатчан белем алу турында килешү төзү конкурс нигезендә башкарыла.

4. Конкурс җирле үзидарә органы тарафыннан игълан ителә һәм җирле үзидарә органында оештырыла торган конкурс комиссиясе тарафыннан уздырыла.

5. Конкурс комиссиясе составына яллаучының вәкиле (эш бирүчесе) һәм (яисә) аңа вәкаләтле булган муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән, муниципаль хезмәт һәм кадрлар, юридик (хокукый) подразделениеләр мәсьәләләре буенча подразделениедән), ә андый подразделениеләр булмаган очракта, гражданин максатчан белем алу турында килешү нигезендә муниципаль хезмәт узарга бурычлы җирле үзидарә органының эшчәнлеген кадрлар һәм юридик (хокукый) озату өчен җаваплы муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр сыйфатында персональ мәгълүматларны күрсәтмичә чакырыла торган фәнни, белем бирү һәм (яисә) башка оешмалар вәкилләре кертелә. Бәйсез экспертлар составы конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе кабул итә торган карарга тәэсир итәргә мөмкин булган мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеген искәртерлек итеп формалаштырыла.

7. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

8. Максатчан белем алу турында килешү төзүгә конкурс уздыру турында мәгълүмат әлеге конкурс уздырылу датасына кадәр бер айдан да соңармыйча “Мензеля” (“Минзәлә”) район газетасында басылырга, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияле челтәрдә җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

9. Гамәлдәге пунктның 8 өлешендә каралганча, конкурс уздыру турында мәгълүматта гражданнарның укуы тәгәлләнгәч башкарырга тиешле муниципаль хезмәт вазифалары төркемнәре; әлеге вазифаларга квалификацион таләпләр; гамәлдәге пунктның 11 өлеше нигезендә конкурска тапшырыла торган документлар исемлеге, аларны кабул итү урыны һәм тәртибе; күрсәтелгән документлар кабул ителергә тиешле срок; максатчан белем алу турында килешү төзүгә кандидатлар сайлау һәм бәя бирү өчен кулланыла торган конкурс процедуралары; язмача бирем темасы (әгәр конкурс комиссиясе файдалана торган конкурс процедураларының берсе язмача бирем булса), шулай ук башка мәгълүмати материалларны сыйдырырга мөмкин.

10. Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет акчалары хисабына көндезге белем алу формасы буенча беренче тапкыр урта махсус һәм югары

белем алучы һәм Россия Федерациясенең дәүләт телен белүче гражданнар максатчан белем алу турында килешү төзүгә конкурста катнашу хокукына ия. Күрсәтелгән конкурста катнашучы гражданин муниципаль хезмәткә кергән вакытка, шулай ук гамәлдәге пунктның 34 өлешендә каралганча, бөтен срок дәвамында, муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль закон билгеләгән таләпләргә туры килергә тиеш.

12. Конкурста катнашырга теләк белдергән гражданин җирле үзидарә органына түбәндәгеләрне тапшыра:

1) шәхси гариза;

3) муниципаль хезмәткә керүче гражданинның (фотографиясен беркетеп) җирле үзидарә органына тапшыру өчен федераль законнар нигезендә расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкетасы;

3) паспорт күчермәсе (паспорт конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

4) хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт эшчәнлеге моңа кадәр алып барылмаган очраклардан тыш);

5) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль закон нигезендә гражданинның муниципаль хезмәткә керү һәм аны узуга каршылык тудыручы авырулары булмау турында медицина оешмасы йомгагы;

6) гражданинның Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет акчалары хисабыннан белем алуның көндезге формасы буенча беренче тапкыр урта махсус һәм югары белем алуын раслаучы белем бирү оешмасы белешмәсе, шулай ук ул үзләштерә торган (һөнәр атамасын, белгечлек яисә әзерлек юнәлешен күрсәтеп) белем бирү программасы турында мәгълүматны сыйдырган, белем бирү оешмасының эчке тәртип кагыйдәләре һәм устав белән күздә тотылган бурычларының үтәлеше турында, укыту планы нигезендә гражданинның арадаш аттестациясен узу нәтиҗәләре турында белешмә.

7) язмача бирем (әгәр конкурс комиссиясе файдалана торган конкурс процедураларының берсе язмача бирем булса).

Җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча гамәлдәге маддәнең 11 өлеше нигезендә гражданин тапшырган документларга кертелгән персональ мәгълүматлар һәм башка мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү башкарыла.

13. Претендентлар сайлана һәм аларга бәя бирелә торган конкурс

комиссиясе утырышы гамәлдәге маддәнең 11 өлешендә күрсәтелгәнчә, документлар кабул итү төгәлләнгәннән соң 14 календарь көннән соңармыйча уздырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс комиссиясе утырышының урыны, датасы һәм вакыты турында андый утырыш уздырылганнан соң өч эш көненнән дә соңармыйча конкурс комиссиясе сәркатибе аша хәбәр алалар. Конкурс комиссиясе утырышын конкурс комиссиясе рәисе, ә ул булмаганда – конкурс комиссиясе рәисе урынбасары уздыра.

14. Конкурс комиссиясе анда гомуми әгъзалар санынnan кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Конкурс комиссиясе карарлары конкурс комиссиясенең утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавыш бирүе аша кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче тавыш биргән карар исәпләнә.

14. Конкурс комиссиясе гамәлдәге маддәнең 11 өлеше 1-6 пунктларында күрсәтелгәнчә, тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча претендентларга бәя бирә. Җирле үзидарә органы карары буенча конкурс процедуралары шәхси әңгәмә, тест уздыру һәм (яки) язмача биремне күздә тота.

17. Шәхси әңгәмә претендентның шәхес сыйфатлары һәм теоретик белемнәренә бәя бирү максатларында претендент конкурс комиссиясе әгъзаларының сорауларына җавап бирә торган аның булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге төренә һәм өлкәсенә караган тема буенча ирекле әңгәмә формасында уздырыла.

18. Теоретик белемнәргә һәм шәхеснең сыйфатларына бәя бирү түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

1) теоретик белемнәр дәрәҗәсе;

2) җавапны логик яктан төзү;

3) грамоталылык һәм сөйләм культурасы;

4) претендентның гомуми белем оешмасында өлгереш дәрәҗәсе, фәнни публикацияләре булу, белем бирү оешмалары уздыра торган фәнни конференцияләрдә, олимпиадаларда һәм башка чараларда катнашуы;

5) һөнәри мотивация булу;

15) җирле үзидарә органнарында практика узу.

19. Шәхси әңгәмә нәтиҗәләренә конкурс комиссиясе әгъзалары бәя бирә:

1) претендент тема эчтәлеген эзлекле, тулы күләмдә ачкан очракта, өч балл;

2)претендент тема эчтәлеген эзлекле, тулы күләмдә ачкан, ләкин төгәлсезлекләр һәм кечкенә хаталар җибәргән очракта, ике балл;

3) претендент тема эчтәлеген эзлекле, әмма тулы күләмдә ачмаган, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргән очракта, бер балл;

4)претендент тема эчтәлеген ачмаган, зур төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргән очракта, ноль бал.

20. Претендентка конкурс комиссиясенең утырышта катнашкан барлык әгъзалары шәхси әңгәмә нәтиҗәләре буенча бирелгән баллар бергә кушыла.

21. Претендентларга тест уздыру җирле үзидарә органнары төзи торган теоретик сораулар исемлеге нигезендә җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору өлкәсендә, шулай ук гражданин максатчан укыту килешүе нигезендә муниципаль хезмәт узачак җирле үзидарә органы эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләрне белүләрен ачыкларлык Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләрен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын белү өчен уздырыла.

22. Тест нәтиҗәләренә бәя бирү претендентның тест сорауларына биргән дөрес җавапларыннан чыгып, конкурс комиссиясе татарфыннан башкарыла.

23. Тест уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары претендентларга түбәндәге билгеләр куя:

1) тест сорауларының 86-100 процентына дөрес җаваплар бирелгән очракта, биш балл;

2) тест сорауларының 70-85 процентына дөрес җаваплар бирелгән очракта, дүрт балл;

3) тест сорауларының 51-69 процентына дөрес җаваплар бирелгән очракта, өч балл;

4)тест сорауларының 35-50 процентына дөрес җаваплар бирелгән очракта, ике балл;

5) тест сорауларының 20-34 процентына дөрес җаваплар бирелгән очракта, бер балл;

6) тест сорауларының 20 процентыннан ким дөрес җавап биргән очракта,

ноль балл.

24. Язмача бирем претендент тарафыннан конкурс комиссиясе билгеләгән һәм конкурс уздыру турында мәгълүматта күрсәтелгән тема буенча басма рәвештә әзерләнә.

25. Язма бирем темасы претендентның җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору өлкәсендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләрен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, шулай ук гражданин максатчан укыту килешүе нигезендә муниципаль хезмәт узачак җирле үзидарә органы эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләрне белүләрен ачыкларлык итеп сайлана.

26. Бирелгән теманы ачуның тулылыгы, бәян итүнең грамоталылыгы, язма сөйләм культурасы язмача биремнең бәя критерийлары булып тора.

27. Язмача бирем конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләнә:

1) претендент язмача бирем темасы эчтәлеген эзлекле, тулы күләмдә ачкан очракта, өч балл;

2)претендент язмача бирем темасы эчтәлеген эзлекле, тулы күләмдә ачкан, ләкин төгәлсезлекләр һәм кечкенә хаталар җибәргән очракта, ике балл;

3) претендент язмача бирем темасы эчтәлеген эзлекле, әмма тулы күләмдә ачмаган, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргән очракта, бер балл;

4)претендент язмача бирем темасы эчтәлеген ачмаган очракта, ноль бал.

28.Конкурс комиссиясенең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан язмача биремгә бәя бирү нәтиҗәләре буенча претендентка бирелгән баллар бергә кушыла.

29. Конкурс кысаларында кулланыла торган конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча иң күп суммар санда балл җыйган претендент конкурста җиңгән санала.

30. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясендә рәислек итүче һәм конкурс комиссиясе сәркатибе тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

31. Конкурс җиңүчесен билгеләү турында конкурс комиссиясе карары җирле үзидарә органы һәм претендент арасында максатчан белем бирү турында килешү төзү өчен нигез булып тора.

32. Конкурста катнашкан гражданнарга ул тәмамланганнан соң бер ай

эчендә язмача формада нәтиҗәләр турында хәбәр ителә.

33. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнарны (конкурс уздырылган урынга бару һәм кайту, торак бинаны наемга алу, яшәү, элемтә һәм башка хезмәтләрдән файдалану һ.б.лар) гражданнар үз хисабыннан башкара.

34. Максатчан укыту тәмамланганнан соң мәҗбүри муниципаль хезмәтен узу срогы максатчан укыту килешүе нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән срок максатчан укыту турындагы килешү нигезендә гражданинга җирле үзидарә органы социаль ярдәм чаралары күрсәткән сроктан азрак, әмма биш елдан күбрәк була алмый.

35. Максатчан укыту турында килешүдә якларның бурычлары һәм җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә максатчан укыту турында килешү белән билгеләнә.

36. Максатчан укыту турында килешү гражданин белән бер тапкыр төзелергә мөмкин.

37. Максатчан укыту турында килешүдә каралган чыгымнарның финанс тәэмин ителеше җирле бюджет хисабыннан башкарыла.

35. Муниципаль хезмәткәрнең персональ мәгълүматлары

1. Муниципаль хезмәткәрнең персональ мәгълүматлары – муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттә алмаштырылучы һәм конкрет муниципаль хезмәткәргә кагылучы вазифа буенча вазифаларын башкару белән бәйле рәвештә яллаучыга (эш бирүчегә) кирәкле булган мәгълүмат.

8. Муниципаль хезмәткәрнең персональ мәгълүматлары Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 14 нче бүлегендә күздә тотылган үзенчәлекләр белән персональ мәгълүматлар өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә эшкәртелергә тиеш.

36. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшен алып бару тәртибе

1. Муниципаль хезмәткәргә шәхси эш ачыла, аңа хезмәткәрнең муниципаль хезмәткә керүе, аны узуы һәм муниципаль хезмәттән азат ителүе белән бәйле документлар беркетелә.

9. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси эше 10 ел дәвамында саклана. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттән киткәндә аның шәхси эше җирле үзидарә органының архивында, муниципаль хезмәтнең соңгы урыны буенча муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә саклана.
10. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазифасын башкарган җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе ликвидацияләнгән очракта, аның шәхси эше ликвидацияләнгән җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, яисә аның хокук күчемлегенә ия булучылар функцияләре тапшырылган

муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә, җирле үзидарә органына саклануга тапшырыла.

11. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшен алып бару дәүләт гражданлык хезмәткәренең шәхси эшен алып бару өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

37. Муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләр реестры

1. Минзәлә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестры алып барыла.

12. Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнне муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.
13. Муниципаль хезмәткәр үлгән (һәлак булган) яисә муниципаль хезмәткәр хәбәрсез югалган дип танылган яисә суд карары белән үлгән дип игълан ителгән очракта, муниципаль хезмәткәр үлгән (һәлак булган) көннең икенче көнендә яисә суд карары законлы көченә кергән көндә муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.

5. Муниципаль хезмәткәрләрнең реестрын алып бару тәртибе муниципаль хокукый акт белән раслана.

38. Муниципаль хезмәтнең кадрлар составын формалаштыруның өстенлекле юнәлешләре

Муниципаль хезмәтнең кадрлар составын формалаштыруның өстенлекле юнәлешләре түбәндәгеләр:

1) һөнәри сыйфатларны һәм компетентлыкны исәпкә алып, муниципаль хезмәт вазифаларына югары квалификацияле белгечләрне билгеләү;

2) муниципаль хезмәткәрләрне хезмәт буенча алга этәрүгә ярдәм итү;

3) муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләү һәм муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирү;

4) кадрлар резервы булдыру һәм аннан нәтиҗәле файдалану;

5) аттестация уздыру аркылы муниципаль хезмәткәрләрнең эш нәтиҗәләренә бәя бирү;

16) гражданнар муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны узганда кадрлар белән эшләүдә кадрларны сайлауның заманча технологияләрен куллану.

39. Муниципаль хезмәттә кадрлар резервы

Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегендә муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазифаларын алмаштыру өчен кадрлар резервы булдырылырга мөмкин.

## IX. Муниципаль хезмәтне финанслау һәм аның үсеш программалары

### 40. Муниципаль хезмәтне финанслау

Муниципаль хезмәтне финанслау муниципаль хезмәткәр күрсәтә торган гарантияләре белән тәэмин итү белән бәйле башка чыгымнарны, пенсия белән тәэмин ителешне, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнарны кертеп, җирле бюджет акчалары хисабыннан башкарыла (әгәр дә федераль закон яисә Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы белән башкача билгеләнмәсә).

### 41. Муниципаль хезмәтнең үсеш программасы

1. Муниципаль хезмәтнең үсеше муниципаль хезмәт үсешенең муниципаль программалары һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджет хисабыннан финанслана торган Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт үсеше программалары белән тәэмин ителә.

14. Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, җирле үзидарә органнарында экспериментлар уздырылырга мөмкин. Гамәлдәге пукнтның 1 нче өлешендә күрсәтелгәнчә, муниципаль хезмәт үсеше программасын тормышка ашыру барышында экспериментлар уздыру тәртибе, шартлары һәм сроклары Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә.

## X. Йомгаклау һәм күчү нигезләмәләре

### 42. Күчү нигезләмәләре

1. Муниципаль хезмәткәрләргә бирелгән квалификацион разрядлар, гамәлдәге Кодекста билгеләнгәнчә, муниципаль хезмәткәрләрнең классны чиннарына түбәндәге тәртиптә тиңләштерелә:

1, 2 һәм 3 нче класслы гамәлдәге муниципаль киңәшченең квалификацион разряды 1, 2 һәм 3 нче класслы гамәлдәге муниципаль киңәшченең класслы чинына тиңләштерелә;

1, 2 һәм 3 нче класслы муниципаль киңәшченең квалификацион разряды 1, 2 һәм 3 нче класслы муниципаль киңәшченең класслы чинына тиңләштерелә;

1, 2 һәм 3 нче класслы муниципаль хезмәт киңәшченең квалификацион разряды 1, 2 һәм 3 нче класслы муниципаль хезмәт киңәшченең класслы чинына тиңләштерелә;

1,2 һәм 3 классլы муниципаль хезмәт референтының квалификацион разряды 1,2 һәм 3 классլы муниципаль хезмәт референтының классլы чинына тәңгәл рәвештә тиңләштерелә;

1,2 һәм 3 классլы муниципаль хезмәт сәркатибенең квалификацион разряды 1,2 һәм 3 классլы муниципаль хезмәт секретаренең классլы чинына тәңгәл рәвештә тиңләштерелә.

2.”Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль закон көченә кергәннән соң, муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт вазифаларында эшләгән чоры билгеләнгән тәртиптә чираттагы классլы чин билгеләү өчен тиешле классլы чинда булу срогы исәпләнә.

3.Муниципаль хезмәткәрләрне социаль гарантияләр белән тәэмин итү максатларында, тиешле елларны хезмәт иткән өчен пенсияләрне финанслау һәм түләү, аларны китергән өчен чыгымнарны да кертеп, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен пенсия белән тәэмин итү өчен каралган тәртиптә һәм шартларда башкарыла.

4. 2020 елның 1 октябренә кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатибе) вазифаларын алмаштыру өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификацион таләпләр – кимендә ике ел һәм кимендә өч ел тәңгәллегендә муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча эш стажы булу өстенә, урта һөнәри белем булуны күздә тотарга мөмкин.

5. 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдәге Нигезләмә һәм муниципаль берәмлекнең башка муниципаль хокукый актлары белән, Татарстан Республикасының 25.04.2015 елдагы “Татарстан Республикасында тәртип саклау җәмәгать пунктлары турында”гы №33-ЗРТ Законы нигезендә, җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу муниципаль хезмәтнең тиешле вазифасы буенча вазифаи бурычлары кергән очракта, муниципаль хезмәт вазифаларының өлкән һәм (яисә) кече төркемнәре вазифаларын алмаштыру өчен һөнәри белем (урта гомуми белем булганда) дәрәҗәсенә квалификацион таләпләр куелмый.